ЧӘРШӘМБЕ
28 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 48 (5848)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

Социалистик терлекчелекне үстерү—сугышчан бурыч

Ашлык мәсьәләсен хәл иткәннән соң большевиклар партиясе һәм Советлар хөкүмәте терлекчелек мәсьәләсен хәл итүне дә бөтен кискенлеге белән куйдылар. ВКП(б) ның XVII нче съездында ясаган докладында иптәш Сталин социалистик терлекчелекне үстерү буенча колхозларга һәм. совхозларга программ күрсәтмәләр бирде. „Терлекчелек эшен бөтен партия, безнең барлык работникларыбыз, партиялеләре дә һәм партиясезләре дә... үз кулларына алырга тиешләр“ диде.

Социалистик терлекчелек үрчесен өчен, терлекчелектән алынган продуктлар мул булсын өчен, промышленностька кирәкле чимал җитәрлек булсын өчен, колхозлар хуҗалыгы тагын да ныгысын, колхозчыларның көнкүреше тагын да яхшырсын өчен Совет дәүләте авылга гаят зур ярдәм күрсәтә. Терлекчелек мәсьәләсе партиябезнең һәм хөкүмәтебезнең һәр вакыт игтибар үзәгендә тора.

Украинада алдынгы колхозчыларның шушы көннәрдә булып үткән киңәшмәсендә иптәш Хрущев терлекчелек турында болай диде: „Терлекчелек, ул—ит, ул—сөт, ул—май, терлекчелек, ул—йон, ә йон—кеше өчен кием-салым; җылы, яхшы, матур кием дигән сүз“.

Болар бик дөрес сүзләр. Без шундый байлыкка ирешү өчен омтылабыз.

Ә безнең республикабыздагы барлык колхозларыбыз да, барлык совхозларыбыз да шуңа ирешү өчен большевикларча көрәшәләрме соң?

Кызганычка каршы, барсы да көрәшә дип әйтеп булмый әле. ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм СССР Совнаркомының „Колхозларда социалистик терлекчелекне үстерү чаралары турында“ үткән ел кабул иткән карарын Татарстан республикасының күп кенә колхозлары һәм совхозлары үтәмәделәр.

Бу карарның үтәлеше Татарстанда менә ничек тора: бездә әлегә кадәр бер генә терлекчелек фермасы да булмаган 13 колхоз, мөгезле эре терлек фермасы булмаган 173 колхоз бар. 278 колхозда бары тик берәр генә ферма исәпләнә.

Яңа фермалар төзү планы үтәлмәде, ә яңа фермаларга терлек туплау планы исә тулаем алганда, хурлыклы рәвештә өзелде. Яңа фермаларга терлекләр туплауда җидди эш булмау нәтиҗәсендә Дөбъяз районының Чапаев исемендәге колхозындагы шикелле бары 6 баш сарыктан торган „фермалар“ да оештырылды. Алар фермабыз бар диләр, фермалы колхоз исмен күтәрәләр. Аерым районнарда, мәсәлән, Куйбышев, Аксубай, Красный Бор, Яңа Чишмә, Дөбъяз һәм Арча районнарында фермалар оештыру пәрдәсе астында зур бозулар булды. Яңа фермалар өчен терлекләрне колхозчылардан һәм колхозчы булмаган хуҗалыклардан сатып аласы урынга, яшәп килә торган фермалардан күчерделәр.

Ә терлекчелек өлкәсендә Биләр, Алексеевский, Әлки һәм Лаеш кебек артта калып баручы районнарда җәмагатьләштерелгән терлекләрне әрәм-шәрәм итү, таркату белән шөгыйльләнү, фермалардагы терлекләрне аерым кешеләргә сату фактлары булган.

Социалистик терлекчелекне алга җибәрү өчен бирелгән дәүләт кредитлары да үткән ел 91,2 процентка гына үтәлде.

Дөрес, Татарстанда терлекчелекне үстерү планын үтәүче колхозлар, гаят зур доход бирә торган фермалар да күп. Мәсәлән, Теләче районының „Марс № 2“ колхозы фермасында, Минзәлә районы Ленин исемендәге колхозның товарлыклы-сөтчелек фермасында, Октябрь, Калинин һәм Тымытык районнарының күп кенә колхоз фермаларында терлекләрнең саны да үсә, товарлыгы да арта, нәселләре дә яхшыра. Ләкин алдынгы фермаларның уңышлары, Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендәге бай тәҗрибәләр киң күләмдә уртаклашылмады, тулы файдаланылмады.

Хәзер партиянең район конференцияләре бара. Конференцияләрдә катнашучы делегатлар район оешмаларының терлекчелек эшенә җитәкчелек итүдәге зур кимчелекләрен большевистик тәнкыйть уты астына алырга, терлекчелек эшендә кискен борылыш ясау өчен конференцияләр конкрет юллар сызып калдырырга тиешләр.

Район советларының башкарма комитетлары, җир бүлекләре терлекләр саны билгеләнгән минимумга җитмәгән колхозларны даими контроль астына алып, яңа фермаларда һәм терлек саны аз булган фермаларда терлек туплау планын һичбер сүзсез үтәүгә ирешергә тиешләр.

Азыкны саклык белән тоту, дөрес тукландыру, яшь терлекләрнең барсын да исән килеш тәрбияләп үстерү терлекләрне кышлату эшендә төп бурыч булып торалар. Бу бурычларны үтәү өчен фермаларда большевистик тәртип урнаштырырга, хезмәтне дөрес оештырырга, зоотехника укуларын өзлексез алып барырга, Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенең тәҗрибәләрен бөтен тулылыгы белән файдаланырга кирәк.

Терлекчелек эшен яхшырту өчен район җир бүлекләрен, совхозларны зоотехниклар һәм ветврачлар белән тәэмин итү гаят әһәмиятле. Ләкин бу тармактагы эш бездә әле дә бик начар тора. Бүгенге хәл шуны күрсәтә. Мәсәлән, 63 районның 18 ндә ветврачлар бөтенләй юк. 1937—38 нче һәм 1939 нчы елларда уку йортларын тәмамлап чыгучы 100 дән артык ветврач Казандагы төрле учреждениедә утыралар. Районнарда 150 дән артык зоотехник, 200 дән артык ветврач җитми. Ләкин Татнаркомзем районнарны белгечләр белән тәэмин итү эшен хәл итүгә большевикларча керешкәне юк әле.

Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә кандидатлар сайлап алу эше терлекчелек буенча дәүләт планын тулысынча һәм арттырып үтәү өчен социалистик ярышны киң күләмдә җәелдерү белән барырга тиеш. 1940 нчы елны социалистик терлекчелекнең куәтле адымнар белән алга бару елы итик!

Чит илләрдә

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 26 февраль. Кичә кич игълан ителгән рәсми белдерүдә болай диелә: „Миномет хәзерләгеннән соң дошман безнең Рейн белән Вогезы арасындагы постларыбызның берсенә атака ясарга маташты, ләкин тиз арада югалтуларга дучар ителеп алып ташланды“.

Бүгенге иртәнге белдерүдә „Фронтның Мозель белән Саар арасындагы күп кенә участкыларында алдынгы частьләрнең активлыгы үскәнлек күренә“ диелә.

БРЮССЕЛЬ, 25 февраль. „Журналь“ газетасының бүгенге хәрби күзәтүендә болай диелгән: „Англия очучылары Вена, Прага өстендә, Гельголанд атавы, Төньяк Германия һәм Төньяк диңгез өстендә берничә разведка ясадылар. Төньяк диңгездә Англиянең сугыш караблары немецләрнең ике су асты көймәсен батырдылар. Германия самолетлары көнчыгыш һәм төньяк Франция өстендә һәм Париж районы өстендә 5 разведка ясадылар. Англия ярлары өстендә немецләр 20 рейд ясадылар“.

БЕРЛИН, 26 февраль. Германия армиясенең верховный командованиесе сводкасында, Эйпель районында Германиянең зенит артиллериясенең бер француз самолетын бәреп төшергәнлеге әйтелә.

БЕРЛИН, 26 февраль. Информация бюросының хәбәр итүенә караганда, кичә Мозельдән көнчыгыштарак уң як флангада французларның 40 лап кешедән торган отряды немецләрнең сакчылык постын пленгә алырга маташкан, ләкин барып чыкмаган. Чик буе полосасында французларның икенче бер разведка отрядының чыгышы да кире кайтарылган.

Германия бухтасы өстендә Германия истребительләре Англия самолетын очратып бәреп төшергәннәр.

БЕРЛИН, 26 февраль. Су асты көймәсе командиры капитан—лейтенант Шульце ерак рейдтән кайткач, дошманның 34.130 тонна авырлыгындагы корабларын батырганлыгы турында рапорт бирде. Сугыш башланганнан бирле бу су асты көймәсе барлыгы 114.510 тонна авырлыгындагы 16 пароходны батырган.

Информация бюросының хәбәр итүенә караганда, сугышның беренче 5 ае эчендә нейтраль илләрнең союзникларга хезмәт күрсәтүче һәм Англиянең 1,8 миллион тоннаждан артыграк караблары батырылган. (ТАСС).

Министрлек портфельләре өчен көрәш

Шушы көннәрдә Монружедә (Париж якынында) „социалистик“ партияләрнең җирле оешмалары җитәкчеләренең сугыш игълан ителгәннән соң беренче конференциясе җыелды. Аны оештыручылар бу гүзәл конференциянең сугыш обстановкасы куйган „иң актуаль мәсьәләләрне“ хәл итәчәген вәгъдә иттеләр.

Менә „Популер“ газетасында бу конференция турында зур отчет чыкты. Конференциядәге чыгышларның иң „әһәмиятле“ темасы—„министрлек портфеле“ турындагы,—„социалистлар“ның хөкүмәткә керүләре турындагы мәсьәлә булган икән. Блюмның иярченнәре үзләренең „хезмәтләрен“ санап күрсәттеләр, күкрәкләрен кактылар һәм Даладье хөкүмәтендә министрлек портфельләре таләп иттеләр.

Конференциядә катнашучыларның берсе—Брейтман болай диде: „1914 нче елны без хөкүмәт составына кергән идек. Без хәзер дә анда булырга тиешбез. Фикер каршылыкларыбызны туктатыйк, җаваплылыкта үз өлешебезне таләп итик“.

Конференциядә катнашучыларның икенче берсе—Дормуа болай диде: „Бу фаҗыйгале көннәрдә хөкүмәткә керү турындагы мәсьәләне хәл итәргә кирәк“. Дормуа „социалистик“ партия җитәкчеләренең—Леон Блюмның һәм Поль Форның хөкүмәт составына керүләрен „бик нык яклады“.

Дормуадан соң ук Блюм речь сөйләде. „Ялкынлы“ речь сөйләп, ул үзе өчен „җаваплылык авыр“ икәнлекне, ләкин әгәр аңа... ышаныч күрсәтсәләр эшнең үзенә терәлеп калмаячагын белдерде.

Конференциядә катнашучыларның бер-икесе халыкның чын настроениесе турында сөйләргә маташып карады. Сена һәм Уаза федерациясе вәкиле бу федерациянең „социалистик“ партиянең парламенттагы группасыннан сугыш шартларында „корбаннарның тигез булуы“ формуласын тормышка ашыруга ирешүен таләп иткәнлеген белдерде. Конференциядә катнашучыларның берсе „солдатларның, крестьяннарның һәм эшчеләрнең мораль һәм материаль шартларын яхшыртырга тырышып карарга“ чакырды.

Ләкин бу оялчан тавышлар министрлек портфельләре өчен көрәшүчеләрнең тәртипсез, ләкин шау-шулы хоры тавышында югалып калды.

26 февраль. (ТАСС).

Төньяк илләр министрләре конференциясенең белдерүе

БЕРЛИН, 26 февраль. (ТАСС). Шушы көннәрдә Копенһагенда Швеция, Норвегия һәм Дания чит ил эшләре министрләренең конференциясе булды. Германиянең информация бюросы конференциянең белдерүен тапшыра. Белдерүдә болай диелә: „Конференция Финляндиядәге вакыйгаларга бәйле булган мәсьәләләрне тикшерде. Чит ил эшләре министрләре үз илләренең нейтралитет политикасы үткәрүләрендә үзләренең бердәмлекләрен расладылар. Илләр өчесе дә нейтралитет политикасын гадел һәм бәйсез рәвештә дәвам иттерәчәкләр“. Аннары белдерүдә әйтелгәнчә, чит ил эшләре министрләре „диңгез сугышын халыкара хокукка каршы килерлек төстә алып баруга каршы бердәм рәвештә протест белдергәннәр. Мондый сугыш нейтраль илләрне зур югалтуларга дучар иткән. Илләрнең өчесе дә бу куркынычны бетерергә тырышуларында бердәм. Аларның хөкүмәтләре сугышучы илләр белән бу мәсьәлә буенча сөйләшүләрдә бер-берсен яклаячаклар“.

Соңыннан белдерүдә „гадел һәм озакка сузылган тынычлык урнаштырырга“ теләк белдерелә.

Рекорд иген уңышы алу өчен көрәш инициаторы, РСФСР Верховный Советы депутаты М. Е. Ефремов (Алтай крае, Белоглазов районының „Искра“ колхозы) Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсе Баш Комитеты карары буенча Зур Алтын медаль белән бүләкләнде. РӘСЕМДӘ: иптәш М. Е. Ефремов.
Н. Калинин фотосы (ТАСС фото-клишесе).

ТАТАРСТАННЫҢ XX ЕЛЛЫГЫНА ХӘЗЕРЛЕК

ЯҢА НОРМАЛАР АРТТЫРЫП ҮТӘЛӘ

Казандагы язу машиналары заводының җыю һәм кою цехлары коллективлары Татарстанның XX еллыгы якынлашу уңае белән алган йөкләмәләрен намус белән үтиләр. Механика цехының Иванова, Ратникова һәм Салахов иптәшләр җитәкчелек итә торган участкылары аеруча яхшы эшлиләр. Иптәш Иванова участкысында көнлек план һәр вакыт 104—207 процент итеп үтәлә. Бу участкы буенча февраль ае планы срогыннан алда үтәлде.

Завод коллективы 20 нче февральдән яңа норма буенча эшли башлады. Яңа нормаларны тикшерү вактында эшчеләр хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да үстерү өчен, алган йөкләмәләрне уңышлы үтәүне тәэмин итү өчен кыйммәтле тәкъдимнәр бирделәр. Хәзер байтак кына эшчеләр яңа норманы яхшы үзләштерделәр. Җыю цехы стахановчысы, комсомолец Хәкимҗанов, механика цехы стахановчыларыннан Овчинников, Галиуллин, Корбанова, Степанов, Акимов, Җамалеттинова һ. б. иптәшләр яңа норманы 144—253 процент итеп үтиләр.

Г. Кушаев.

РАЦИОНАЛИЗАТОРЛАР

Зеленодольск шәһәрендәге 3 нче номерлы фанер заводы рационализаторлары республикабызның XX еллыгын зур уңышлар белән каршылау өчен көрәшәләр. Узган ел алар тарафыннан кертелгән тәкъдимнәрне тормышка ашыру заводка 132 мең сумлык экономия биргән булса, быел моны 5 миллион сумга җиткерү йөкләмәсе алынды.

Йөкләмәләр практик эш белән ныгытыла. Мәсәлән, актив рационализаторлардан Рәхмәтуллин, Гыйльфанов, Фәйзерахманов, Фелин һәм күп кенә башка иптәшләр тарафыннан кертелгән яңа тәкъдимнәрне тормышка ашыру хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү белән бергә, күп кенә сумага экономия ясау мөмкинлеген бирә, хезмәтне җиңеләйтә. Шәһәр Советы депутаты иптәш Коровен үзе эшли торган фрезер станогын рационаллаштыру аркасында нормасын системалы рәвештә 180—200 процент итеп үтәүгә ирешә.

Инженер-техник работниклардан Прохоров, Шнурков иптәшләр тарафыннан кертелгән тәкъдимнәрне тормышка ашыру һәр елны 32 мең сум экономия ясау мөмкинлеген бирә.

Завод идарәсе бу тәкъдимнәрне тормышка ашыру өчен практик чаралар күрә башлады.

И. Фәйзуллин.

СТАХАНОВЧЫ БРИГАДАЛАР

Кинопленка төзелеше эшчеләре Татарстан республикасының XX еллыгына хәзерләнәләр. Икенче участкыдагы иптәш Җиһаншин бригадасы башкаларга үрнәк күрсәтә. Стахановчылардан Галимуллин, Әхметшин, Хәйруллин һәм башка иптәшләр норманы ике тапкыр арттырып үтиләр. Бригада членнары төрле профессияләрне тырышып үзләштерәләр.

Иптәш Серков җитәкчелек итә торган бригаданың членнары барсы да стахановча эшләп, норманы ике тапкыр һәм аннан да арттырып үтәүгә ирешәләр. Бригада январь ае планын 171 процент итеп үтәгән иде. Ул февраль аенда да алда бара.

Р. Галиева.

ГЫЙЛЬМИ ДӘРӘҖӘ АЛУГА ТӘКЪДИМ ИТҮДӘ ЯҢА ТӘРТИП

СССР Совнаркомы янындагы югары мәктәп эшләре комитеты институтларның фәнни - педагогика работникларын гыйльми дәрәҗә алуга тәкъдим итүдә яңа тәртип кертте.

Югары уку йортлары советлары фәннәр докторы дигән гыйльми дәрәҗәсе булган һәм кафедра мөдирләре итеп расланган яки конкурс буенча кафедра профессоры хезмәтенә сайланган кешеләрне профессор дәрәҗәсе бирелүгә тәкъдим итә алалар. Доцент дәрәҗәсе алуга фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәсе булган һәм штатлы доцент хезмәтендә эшләүче яки бу хезмәткә конкурс буенча сайланган кешеләр тәкъдим ителә алалар.

Зур производство стажы булган һәм югары уку йортларында укытучылык эшенә тартылган югары квалификацияле белгечләрне, конкурс буенча сайлаганнан соң һәм югары уку йортында ярты ел буена уңышлы педагогия эше алып барганнан соң аларны профессор яки доцент дигән гыйльми дәрәҗә алуга тәкъдим итәргә мөмкин.

Фәнни-тикшерү институтларының профессоры һәм өлкән фәнни сотрудникы дигән дәрәҗәне алуга доктор һәм фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәләре булган һәм институтта тиешле хезмәттә эшләүче кешеләр тәкъдим ителәләр.

Гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр бирү, конкурс буенча хезмәт дәрәҗәләренә сайлау ВУЗ ларның һәм фәнни - тикшерү институтларының советларында яшерен тавыш бирү тәртибендә үткәрелә. Әгәр тавыш бирүдә советның расланган членнарының кимендә өчтән ике өлеше катнашса, тавыш бирү дөрес дип санала.

(ТАСС).

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

26 нчы февральдә **Карелия бугазында** безнең частьләр дошманның ныгытмаларын юк итүне дәвам иттерделәр. Дошманның безнең частьләргә каршы атака ясарга маташулары кире кагылды һәм ул зур югалтуларга дучар ителде. Безгә каршы атакаларның берсендә дошманның 5 танкысы сафтан чыгарылды, шуларның 3 сен безнең частьләр алдылар.

Өстәмә хәбәрләргә караганда, **Койвисто (Бьеркэ)** атавында, 24 нче февральдәге сводкада күрсәтелгән сугыш кирәк-яракларыннан тыш, безнең частьләр дошманның 26 ныгытылган оборона пунктын алганнар, шуларның 15 е тимер-бетоннан ясалган артиллерия корылмалары. Болардан тыш 2 крепость казаматы, кораллар һәм азык тутырылган 4 склад, 10.000 снаряд, 5.000.000 нан артык патрон кулга төшерелгән.

Фронтның башка участкыларында әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

Безнең авиация дошманның гаскәрләренә һәм аның сугыш объектларына актив сугыш хәрәкәтләре алып барды. Һавада булган сугышларда дошманның 19 самолеты бәреп төшерелде.

ВКП(б) ның КАЗАН ШӘҺӘР ОЕШМАСЫНЫҢ V нче КОНФЕРЕНЦИЯСЕ ДЕЛЕГАТЛАРЫ ИГТИБАРЫНА

Партиянең шәһәр күләмендәге V нче конференциясе шушы елның 3 нче мартында, 18 сәгатьтә Менжинский исемендәге клуб бинасында ачыла.

Делегатлык билетлары һәр көнне иртән 9 сәгатьтән 15 сәгатькә кадәр һәм 17 сәгатьтән 21 сәгатькә кадәр ВКП(б) ның Шәһәр Комитеты бинасында 19 нчы бүлмәдә бирелә. (Астрономический урам, 15/19).

Оештыру комиссиясе.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Соңгы көннәрдә Наньнин—Биньян шоссесендә каты сугышлар булган. Төп сугышлар Цзяотан тирәләрендә булган. Кытай гаскәрләре японнарның атакаларын кире какканнар һәм аларны Саньтанга чигенергә мәҗбүр иткәннәр.

22 нче февральдә кытай частьләре Циньчжоудан төньяктарак Сяодун якынында японнарның позицияләренә атака ясаганнар. Сугышларда японнарның 300 ләп кешесе үтерелгән һәм яраланган. Японнар күп кенә сугыш кирәк-яракларын югалтканнар.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Аньхуэй провинциясендә кытай гаскәрләре уңышлы операцияләр ясап Лучжоуга һөҗүм итәләр.

Кытай хәбәрләренә караганда, 21 нче февральдә Шанхай—Ханчжоу тимер юлының көньяк участкысында күп кенә пунктларның кытайлар тарафыннан алынуы аркасында поездлар хәрәкәте тукталган. 24 нче февральдә кытай частьләре Ханчжоудан 25 километр төньяк-көнчыгыштарак Юнпин станциясенә атака ясаганнар. Бу секторда көрәш дәвам итә.

ГУАНДУН ПРОВИНЦИЯСЕНДӘ

ЧУНЦИН, 26 февраль. (ТАСС). Чунцинга Гуандун провинциясе хөкүмәте председателе килгән. Сентрал ньюс агентлыгының хәбәрчесе белән ясаган беседасында ул Гуандун провинциясенең төньяк өлешендәге хәл турында сөйләгән. Аның әйтүенчә, рәсми саннарга караганда, андагы операцияләр вактында японнар тыныч халыктан 3.800 кешене үтергәннәр һәм 70 меңләп кешене яралаганнар. Чигенгән вакытта японнар крестьяннарның 26 меңнән артык йортларын яндырганнар, 5 мең баштан артык терлекне юк иткәннәр.

ПАРТИЯНЕҢ РАЙОН КОНФЕРЕНЦИЯЛӘРЕНДӘ

ЛЕНИН РАЙОНЫНДА

26 нчы февральдә иртәнге һәм кичке утырышларда райком һәм ревизия комиссиясе отчетлары буенча фикер алышулар дәвам итте. Барлыгы 28 делегат чыгып сөйләде.

Кичә конференция райкомның отчет доклады буенча резолюция кабул итте. Конференция ВКП(б) район комитетының политик линиясен дөрес, ә практик эшен канәгатләнерлек дип тапты.

Шул ук көнне конференция ябык (яшерен) тавышка кую тәртибендә, район комитетының пленум составына 35 член һәм 27 кандидат сайлады. Партиянең Казан шәһәре конференциясенә тавыш бирү хокукы белән 32, киңәш бирү хокукы белән 10 делегат сайланды.

Шуның белән конференция үзенең эшен тәмамлады.

Г. Миңнул.

БАУМАН РАЙОНЫНДА

Бауман районы большевикларының XIV нче конференциясе зур оешканлык белән башланды. Делегатларның барсы да дип әйтерлек билгеләнгән вакытта килделәр һәм конференциянең җитәкче органнарын эшлекле рәвештә сайладылар. Почетлы президиум сайлау турындагы такдим конференция делегатлары тарафыннан көчле алкышлар белән каршыланды. Иптәш Сталин исмен делегатлар аяк өсте басып хөрмәтләделәр.

ВКП(б) райкомының отчет чоры эчендәге эше турындагы докладны райкомның беренче секретаре иптәш Суганов ясады. Соңгы вакытта һәм бигрәк тә ВКП(б) ның XVIII нче съездыннан соң партиянең Бауман район оешмасы шактый уңышларга ирешкән. ВКП(б) сафларын үстерү буенча райком тарафыннан зур эш үткәрелгән булуын аеруча әйтеп үтәргә кирәк. Отчет чоры эчендә партиянең район оешмасы составы 66,2 процентка үсүе моны ачык күрсәтә.

Яш коммунистлар белән эшләү, активны партия эшенә тарту, райком аппаратын кадрлар белән ныгыту, комсомол, профсоюз оешмаларына һәм ирекле оешмаларга җитәкчелекне көчәйтү, кадрлар сайлап алу һәм яш кадрларны тәрбияләү буенча да күп кенә эшләр үткәрелгән.

Шуның белән бергә, райкомның практик эшендә зур гына җитешсезлекләр дә бар әле. Бу кимчелек, барыннан да элек, партия пропагандасы өлкәсендә, агитация-масса эшләре өлкәсендә, төп профессия эшчеләрне партия сафларына тарту һәм коммунистлары аз санлы булган башлангыч партоешмаларга җитәкчелек өлкәсендә, резерв белән эшләү һәм үтәлүне тикшерү өлкәсендә аеруча күзгә бәрелә. Конференция делегатлары бу кимчелекләргә җидди игтибар бирергә һәм аларны бетерү буенча конкрет күрсәтмәләр ясарга тиешләр.

Конференциянең бүгенге утырышында доклад буенча фикер алышулар башлана.

М. Ш.

МОЛОТОВ РАЙОНЫНДА

Кичә, В. И. Ленин исмендәге Дәүләт университетының актовый залында Молотов районы партия оешмасының 5 нче район конференциясе эшен башлады. Конференция эшендә 201 кеше тавыш бирү һәм 41 кеше киңәш бирү хокукы белән катнаша.

Делегатлар почетлы президиумга бөек юлбашчыбыз даһи Сталинны һәм аның иң якын көрәштәшләрен—ВКП(б) Үзәк Комитетының Политбюро членнарын зур күтәренкелек белән һәм көчле алкышлар астында сайлыйлар.

Конференциянең җитәкче органнары сайланганнан соң, сүз, райкомның эше турында отчет доклады өчен райком секретаре иптәш Палагинга бирелә.

— Отчет чорында,—ди иптәш Палагин,—партиянең Молотов район оешмасы зур уңышларга иреште. ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарлары нигезендә эшне яңа баштан кору, карарларның үтәлешен тикшерү, оператив җитәкчелекне көчәйтү алда торган бурычларны хәл итүдә күп ярдәм иттеләр.

Үзенең докладында иптәш Палагин практик эштә булган кимчелекләр турында, аерым мәсьәләләрдә булган җитешсезлекләр турында сөйләде. Отчет чорында партия оешмасы партия сафларына 302 член һәм 634 кандидат кабул иткән. Бу, оешманың 41,6 процентын тәшкил итә. Шулай да партия сафларын лаеклы, үзләрен практик эштә күрсәткән иптәшләр хисабына үстерү мәсьәләсендә җитешсезлекләр күп әле.

Райком партия сафларын үстерү мәсьәләсенә тулы җитәкчелекне тәэмин иткән дип булмый. Икмәк заводы, микробиология институты, балык тресты янындагы патроешмаларның бер генә кешегә дә үсмәвен тагын нәрсә белән аңлатырга соң?

Партия пропагандасын оештыру өлкәсендә Молотов районы республикабызның үрнәк районнарыннан берсе булырга тиеш иде. Чөнки Молотов районында булган көч башка районнарга караганда күп өлеш артык. Дөрес, район коммунистларының күпчелеге (1.591 кеше) ВКП(б) тарихын үзлекләреннән өйрәнә. Теоретик беседалар, конференцияләр еш кына үткәрелә. Ләкин, шуңа карамастан, бу эш тиешенчә оештырылган дип булмый әле. Район парткабинетында эшнең торышы начар, ул партиянең башлангыч оешмалары белән тыгыз элемтәдә түгел. Аерым җитәкче кадрлар партия тарихын өйрәнүгә әһәмият биреп җиткермиләр.

Бүген ревизия комиссиясенең отчет докладын тыңлаганнан соң, докладлар буенча фикер алышулар башлана.

Р. Баһау.

Партиянең Киров район конференциясендә. М. Солтанов фотосы.

СТАЛИН РАЙОНЫ КОММУНИСТЛАРЫНЫҢ XV НЧЕ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Эшчеләр сыйныфының бөек даһилары—Маркс, Энгельс, Ленин һәм Сталин портретлары белән, бөек Сталинның иң якын көрәштәшләренең портретлары белән, кызыл байраклар белән, гөлчәчәкләр белән бизәлгән, җыйнак итеп җыештырылган, якты клуб залына партиянең Сталин район конференциясе делегатлары бердәм рәвештә җыелдылар.

Конференциядә тавыш бирү хокукы белән 209 һәм киңәш бирү хокукы белән 54 делегат катнаша.

Конференциянең җитәкче органнарын сайлаганнан соң, почетлы президиум сайлау турында такдим кертелә. Делегатлар бу такдимне алкышлап каршы алалар. Почетлы президиумга Сталин, Молотов, Ворошилов, Каганович, Калинин, Жданов, Андреев, Микоян, Хрущев, Берия, Шверник, Димитров, Куусинен, Тельман иптәшләр сайланды.

ВКП (б) райкомы секретаре иптәш Штин райкомның 22 айлык эше турында отчет доклады ясады. Аннары, ревкомиссиянең отчеты тыңланды.

Бүген һәр ике доклад буенча фикер алышулар дәвам итә.

ЧЕПЬЯ РАЙОНЫНДА

ЧЕПЬЯ, 27 февраль. (Үз хәбәрчебездән телефон буенча). Партиянең район җыелышы зур күтәренкелек белән башланды.

ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Фәйзуллин үзенең отчет докладында партиянең район оешмасы состав ягыннан шактый үскәнлеген, коммунистларның партия эшендә һәм производствода активлыгы көчәйгәнлеген күрсәтеп үтте. Үткән сайлаулар вактында районда ике башлангыч партоешма булган булса, хәзер аларның саны 13 кә җиткән. Шуның өстенә тагын 11 урында кандидатлар группалары бар. Отчет чорында партия сафларына 156 кеше кабул ителгән. Ләкин төп профессия работниклары һәм хатын-кызлар исәбенә үсеш һич тә җитәрлек түгел. Хатын-кызлардан бары 19 гына кеше партиягә алынган.

Районда партияле һәм партиясез большевикларны җитәкче эшләргә күтәрү буенча да беркадәр эшләр үткәрелгән. Яш коммунистлардан 28 кеше җитәкче оешмаларда эшли.

Партия пропагандасының куелышы турында ВКП(б) Үзәк Комитетының карары чыкканнан соң күп кенә коммунистлар, комсомолецлар һәм интеллигентлар партия тарихын үзлекләреннән өйрәнергә теләк белдергәннәр. Ләкин аларның күбесе бу өлкәдә канәгатләнерлек эшләми. Партиянең район активы арасында бу эш шулай ук начар тора. Райком членнарыннан Петров, Әхметшин һәм Вафин иптәшләр „Кыскача курс“ ның әле беренче-икенче бүлекләрен генә өйрәнәләр. Партия тарихын өйрәнү буенча оештырылган дүрт түгәрәкнең берсе җитәкче „булмаганлыктан“ таратылган.

ВКП(б) райкомы кабул ителгән карарларның үтәлешен тикшерү мәсьәләсе белән дә җитәрлек шөгыльләнмәгән. Политик һәм хуҗалык мәсьәләләре, партия-масса эшләре буенча чыгарылган карарларның бик аз өлеше тикшерелгән.

Докладчы партиянең район җыелышы карарының ничек үтәлүе турында һәм райком членнарының эшләре турында конкрет бер нәрсә дә әйтмәде.

Х. Галләмев.

БИЛӘР РАЙОНЫ

26 нчы февральдә партиянең Биләр район конференциясе ачылды.

Конференция почетлы президиумга ВКП(б) Үзәк Комитетының Политбюро составын сайлады. Делегатлар бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин хөрмәтенә көчле алкышлар ясадылар.

ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Вафин отчет доклады белән чыкты. Отчет чорында партиянең район оешмасы 91 процент, ә башлангыч партоешмалар саны 50 процент үскән. Докладчы, партоешманың авыл хуҗалыгындагы иң алдынгы кешеләр — алдынгы тракторчылар, комбайнчылар һәм бигрәк тә хатын-кызлар исәбенә йомшак үсүен күрсәтте.

Конференциянең икенче көнендә отчет доклады буенча фикер алышулар башланды. (ТатТАСС).

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕК

АЛДЫНГЫЛЫКНЫ ЯУЛАП АЛЫРБЫЗ

Кызыл Йолдыз районының Б. Сукачы авылындагы „Трактор“ колхозы язгы чәчүгә хәзерлекне төгәлләде.

Авыл хуҗалыгы машиналарына һәм инвентарьларга яхшы сыйфатлы ремонт ясалды, акт белән бригадаларга тапшырылды. Барлык чәчү мәйданына җитәрлек орлык хәзерләнде. Аларның сыйфаты яхшы. Кар тоту, кырга тирес чыгару һәм җирле ашламалар җыю, торф чыгару планнары 100 процент үтәлде. Хәмидуллин һәм Шәйдуллин иптәшләрнең бригадалары бу чараларны арттырып үтәделәр.

Агротехника түгәрәге яхшы эшли. Бу түгәрәктә 60 кеше укый. Аларның 40 проценты хатын-кызлар. 11 занятие үткәрелде инде. Язгы чәчүгә хәзерлек эшенә колхоз председателе иптәш Шәмиев оператив җитәкчелек итә.

Без ирешелгән уңышлар белән чикләнергә ярамавын беләбез. Бу уңышларны тагын да ныгыту өчен социалистик ярышны киң җәелдерәбез. 1940 нчы елда югары уңыш алу өчен „Акчура“ колхозын ярышка чакырдык. Ярышта алдынгылыкны яулап алырбыз.

Николай Семенов.
Комсомол комитеты секретаре.

АГРОТЕХНИКА ЧАРАЛАРЫ ПЛАНЫ АРТТЫРЫП ҮТӘЛДЕ

Кукмара районы, Ашбуҗи авылы, „Стахановчы“ колхозы йөзпотчылар хәрәкәтенә районда беренче булып кушылган иде. Колхоз членнары моңар ирешү өчен нык көрәш алып баралар. Колхозда кар тоту планы 200 процент, көл җыю—227 процент, басуга тирес чыгару 100 процент һәм компост ашлама хәзерләү планы 146 процент үтәлде инде. Барлык бригадаларда да даими звенолар оештырылды. Стахановчылар мәктәбе һәм агротехниканы өйрәнү түгәрәге дә бар. Аларда занятиеләр тәртипле рәвештә бара. Агротехниканы өйрәнү түгәрәгенә Юсупҗан иптәш Әхмәтҗанов җитәкчелек итә. Югары иген уңышы өчен көрәштә иптәш Әхмәтҗановның бай тәҗрибәләре бар. Мәсәлән, ул 1937 нче елны ук инде колхозның тәҗрибә участкыларында арышның һәр гектарыннан 32,5 центнер һәм бәрәңгенең һәр гектарыннан 300 центнер уңыш алуга ирешкән иде. Колхозчылар иптәш Әхмәтҗановның эш методларын зур кызыксыну белән өйрәнәләр.

Гали Галиев.

ЯРЫШТА ҖИҢҮ ӨЧЕН

Кызыл Юл районының Чапаев исмендәге колхозы язгы чәчүгә отлично хәзерләнү өчен „Кызыл Таң“ колхозы белән ярыша. Колхозчылар ярыш договорын тулысынча үтәү өчен зур дәрт белән көрәшәләр. Һәрбер колхозчы үзара ярышып эшли. Нәтиҗә начар түгел. Колхоз язгы чәчүгә хәзерлектә зур гына уңышларга ирешә. Орлык туплау һәм чистарту эшләре төгәлләнде. Чәчү машиналары һәм инвентарьлар ремонттан яхшы сыйфатлы итеп чыгарылды. Аларны комиссия акт белән кабул итте. Ремонтта эшләүчеләрдән Әхметҗанов һәм Низамов иптәшләр көнлек норманы 105—110 процент үтәделәр.

Агротехника чаралары да уңышлы үткәрелә. Кар тоту планы 135 процент үтәлде. 800 йөк тирес чыгарылды. Басуга тирес чыгаруда Әхметҗанов, Нигмәтҗанов һәм Сабиров иптәшләр норманы 150—170 процент үтиләр.

Агротехника түгәрәгендә занятиеләр план белән алып барыла. Анда 25 кеше укый. Нәҗмиева, Шакирова, Хасанова һәм Ибраһимова иптәшләр үтелгән темаларны отлично билгесенә үзләштереп баралар.

А. Сафин.

ЮГАРЫ ОСЛАНДА АШЫКМЫЙЛАР

Шушы көннәрдә Югары Ослан районында колхоз председательләренең киңәшмәсе булып үтте. Анда „1940 нчы елгы язгы чәчүгә хәзерлек турында „ВКП(б) Өлкә Комитетының VIII нче пленумы карары һәм ВКП(б) райкомының X нчы пленумы карары тикшерелде.

Районның күп кенә колхозларында язгы чәчүгә хәзерлек эшләре гафу ителмәслек начар. „Красный ключ“, „Заречный“, „Победитель“ һәм башка күп кенә колхозларда авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт башланмаган. Кышкы агротехника чаралар планын үтәү дә канәгатләнерлек түгел. „Трактор“ һәм „Идел“ колхозларында басуга тирес чыгару планы 33—40 процент кына үтәлгән.

Кайбер колхозларда чәчүлек орлыклар җитәрлек тупланмаган. „Красный ключ“ колхозында 180 центнер, „Трактор“ колхозында 150 центнер чәчүлек орлык җитми.

Югары Ослан районы колхозлары шәһәр хезмәт ияләрен яшелчә белән тәэмин итү өчен дә нык көрәшергә тиешләр. Моның өчен барыннан да элек яшелчә орлыкларын җитәрлек кадәр хәзерләргә һәм парникларны яраклы хәлгә китерергә кирәк. Яшелчә орлыклары районның бер генә колхозында да җитәрлек хәзерләнмәгән әле.

Киңәшмә ВКП(б) Өлкә Комитетының VIII нче пленумы карарын үтәү өчен практик чаралар билгеләде.

Г. Ризванов.
И. Җамалиев.

УРЫНЛЫ ТӘНКЫЙТ

Киров районы большевикларының конференциясе делегатларның зур активлыгы белән үтә. Доклад буенча фикер алышулар моны ачык күрсәтә. Чыгып сөйләүче делегатлар отчет чорында райком тарафыннан башкарылган эшләргә, партиянең тарихи XVIII нче съезд карарларын тормышка ашыру буенча ирешелгән уңышларга тукталу белән бергә, райкомның һәм аның бүлекләренең эшендәге кимчелекләрне тәнкыйтлиләр һәм аларны бетерү юлларын күрсәтәләр.

Отчет чорында Киров районында ирешелгән уңышлар шактый зур. Бу вакыт эчендә районда иң алдынгы кешеләрдән 1.273 иптәш партия сафларына алынган. Коммунистлардан 1.165, комсомолецлардан 1.380 кеше „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ н үзлекләреннән өйрәнә. Практик эштә сыналган иптәшләрдән 125 кеше район күләмендә җитәкче эшләргә күтәрелгән. Мисаль өчен 6 нчы тегү фабрикасы, агач заводы, Казан пристане янындагы башлангыч партоешмаларга секретарь итеп күтәрелгән Алексеева, Платонова, Васильев, 5 нче тегү фабрикасына директор итеп күтәрелгән Бакирова, райкомның агитация-пропаганда бүлеге мөдире итеп күтәрелгән Шепетова һәм башка күп кенә иптәшләрне күрсәтергә мөмкин.

Райондагы промышленность предприятиеләренең күпчелеге системалы рәвештә производство заданиеләрен үтәп бара. 1 нче номерлы күн заводы 1939 нчы ел планын 115 процент, „Промкооператор“ артеле — 105 процент, 6 нчы тегү фабрикасы—101 процент итеп үтәде. Соңгы ике ел эчендә райондагы промпредприятиеләрнең продукциясе 1937 нче ел белән чагыштырганда, 62 миллион сумга артты. Хезмәт җитештерүчәнлеге 18 процент үсте.

Шундый уңышлар булу белән бергә, райкомның һәм аерым башлангыч партоешмаларның эшендә җидди кимчелекләр бар. Райондагы аерым предприятиеләр үзләренең производство планнарын елдан-ел үтәми киләләр. Районның иң зур предприятиеләренең берсе булган җитен комбинаты 1938 нче ел планын 83 процент, 1939 нчы ел планын бары 55 процент үтәгән. Шулай ук „Урак һәм чүкеч“ заводы, 5 нче тегү фабрикасы һәм башка кайбер предприятиеләр соңгы ике елда производство планнарын үтәмәгәннәр.

Бу предприятиеләрнең начар эшләвендә райкомның гаебе зур. Райком ул предприятиеләрне эштә сыналган кадрлар белән ныгытуга тиешенчә игтибар бирмәгән. Андагы партоешмаларга эшлекле ярдәм күрсәтмәгән. Мәсәлән, узган елны „Урак һәм чүкеч“ заводы янындагы партоешмада 4 тапкыр секретарь алмаштырылган. Билгеле, бу хәл партия-политик эшне түбәнәйтүгә, завод администрациясе эшенә партоешманың контрольлек итүен йомшартуга китергән. Райкомның промпредприятиеләргә җитәкчелек итүен тәнкыйтләп, иптәш Шпаков болай ди: „Райком җитен комбинатының артта калуын теркәп кенә барган. Аңа җитәкчелек итмәгән. Предприятиеләрдә яңа нормалар кертү эше белән шөгыльләнмәгән. Һәм шуңа күрә ул мәсьәләләр докладта бөтенләй чагылдырылмады“.

Киров районы Казан шәһәренең промышленность районнарыннан берсе. Шулай булгач, бу районда партия сафлары беренче чиратта иң алдынгы эшчеләр хисабына, төп профессия кешеләре хисабына үсәргә тиеш иде. Фактта исә эшнең торышы бөтенләй башкача. 1939 нчы елны партия сафларына кандидат итеп кабул ителүчеләр арасында эшчеләр бары тик 28,5 процент. Алдынгы хатын-кызлар хисабына үсеш тә шәптән түгел. Партия сафларына җитәрлек тикшермичә алу фактлары да бар. Мәсәлән, Орлов дигән кеше ВКП(б) га кандидат итеп алына һәм дини гореф-гадәтләрне үтәгәне өчен озак та үтми райком аны партия сафыннан чыгарырга мәҗбүр була.

Коммунистларның теоретик белем дәрәҗәләрен күтәрү һәм партия-политик эшенең торышы канәгатләнерлек түгел. Шуның аркасында аерым коммунистлар арасында партия һәм производство дисциплинасын бозу, үзләренең партбилетларын саклауга игтибарсыз карау һәм башка фактлар бар.

Делегатлар райкомның бүлекләре арасында тиешле бәйләнеш булмауны һәм аерым бүлекләрнең башлангыч партоешмаларга эштә йомшак ярдәм күрсәтүләрен большевистик тәнкыйт уты астына алдылар.

— Райком инструкторлары башлангыч партоешмаларга, күп вакытта, аерым мәсьәләләр буенча маглүматлар алу өчен генә киләләр. Теге яки бу мәсьәләне хәл итүдә ярдәм күрсәтү өчен аларның партҗыелышларга килүләрен сорасаң, төрле сәбәпләр табалар һәм килмиләр, ди иптәш Фролов (Юл участкысы партоешмасы секретаре). Хәмидуллин (Ленин заводы), Алексеева (6 нчы тегү фабрикасы) иптәшләр кайбер көннәрне бер партоешмага райкомнан 5—6 инструктор килүнең эш өчен файдасыз булуы турында сөйләделәр.

27 нче февральдә конференциянең кичке утырышында отчет доклады буенча фикер алышулар дәвам итте.

Ә. Ишкаев.

ЯҢА ЖИРГӘ КҮЧӘЛӘР

Патша Россиясенең төрмәсе булып саналган, надан, кыргый Себер хәзер, Совет власте елларында, бигрәк тә беренче һәм икенче бишьеллыклар чорында союзда алдынгы, социалистик крайларның берсе булып әверелде.

Менә Себернең матур бер почмагы—Бурят-Монголия республикасы. Анда формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик культура чәчәк ата.

Совет власте елларында Бурят-Монголиянең авыл хуҗалыгы зур адымнар белән алга китте. Аның табигый шартлары авыл хуҗалыгын, аеруча терлекчелекне үстерү өчен чикләнмәгән мөмкинлекләр бирәләр. Ул терлекчелек буенча Союзыбызда иң бай, иң алдынгы республикаларның берсе.

Ләкин әле Бурят-Монголиядәге иксез-чиксез байлыкларның хәзергә барсы да үзләштерелеп җитмәгәннәр. Республика бу мөмкинлекләрнең барсын да табигать кулыннан тартып алып, халык файдасына, ил файдасына бирү өчен яңа көчләр көтә. Шуңа күрә дә безнең Татарстаннан күп кенә хуҗалыкларның Бурят-Монголиягә күчеп китәргә теләүләре бик табигый.

Соңгы вакытта Татарстаннан Бурят-Монголия республикасына күчерүне сорап Татсовнаркомның күчерү управлениесенә 665 хуҗалыктан гариза алынган иде. Күчеп китүчеләргә 500 дән артык күчү билеты бирелде инде.

Бурят-Монголиягә китүчеләр кайсы районга, кайсы колхозга барулары, ул колхозның экономикасы турында яхшы беләләр. Менә, Татарстан колхозчылары бара торган Энгельс исмендәге колхоз. Бу колхозның җир мәйданы 32.876 гектар. Биредә 2 меңнән артык сыеры булган ферма, 700 дән артык ат, 350 дән артык сарык бар һ. б.

Күчеп китүчеләргә дәүләт тарафыннан зур льготалар бирелә. Оешкан рәвештә күчеп китүчеләр поездда түләүсез баралар (терлекләре һәм йорт әйберләре дә түләүсез алып барыла). Билгеләнгән урынга барып җиткәнче түләүсез ашау-эчү белән һәм медицина ярдәме белән тәэмин ителәләр. Яңа җиргә барган хуҗалыклар һәм алар урнашкан колхозлар (Бурят-Монголиядә) 6 елга кадәр акчалата һәм натуралата барлык төр түләүләрдән азат ителәләр.

Күчеп барган хуҗалыкларга барган авылларында һәм колхозларында хәзерләнгән йорт һәм корылмалар җитешмәгәндә, аларны төзү өчен ссуда тәртибендә акча бирелә. Төзү өчен тотылган акчаның 35 проценты дәүләт бюджеты хисабына алына. Ә калган суманы һәрбер хуҗалык ссуда алганнан соң 3 ел үткәч түли башлый һәм аны түләп бетерү өчен 10 ел срок бирелә. Әгәр китүчеләр арасында сыерсыз хуҗалыклар булса, мондый хуҗалыкларга сыер алу өчен һәм йорт җиһазлары булдыру өчен, шулай ук, һәр хуҗалыкка озак сроклы кредит бирелә.

М. Хәмидуллин.

ЯРЫШКА ФОРМАЛЬ КАРАШ

Дөбъяз районы үткән ел Әтнә һәм Биектау районнары белән социалистик ярыш договоры төзегән иде. Ел үтеп китте. Ләкин ярыш договорының үтәлеше бер генә тапкыр да тикшерелмәде.

Бу районның күп кенә колхозларында да социалистик ярышка шундый формаль караш фактлары бар. „Марс № 2“, „Үзәк“, „Таң“, „Комбайн“, „Чурнаш“, „Спартак“ һ. б. колхозларда төзелгән социалистик ярыш договорлары кәгаздә генә калды. Ярыш договоры буенча алынган йөкләмәләрнең үтәлеше вактында тикшерелмәде.

Х. Латыйпов.

ФИНЛЯНДИЯ ВАКЫЙГАЛӘРЕНЕҢ ХАЛЫКАРА ХАРАКТЕРЫ

Менә өч айга якын инде, Финляндия мәсьәләсе бөтен дөньяның игтибар үзәгендә тора. Франция, Англия, Америка һәм Скандинавия газеталарын укыганда, хәттә Германия белән Франция һәм Англия арасындагы сугыш арткы планга киткән кебек күренә, хәттә Кытай белән Япония арасында да бернинди дә сугыш юк кебек, Япония белән Кушма Штатлар арасында бернинди дә кискен конфликт юк кебек, бары тик „батыр“, „прогрессив“, „социаль фин демократиясе“ генә бар кебек күренә.

Бөтен дөньядагы буржуаз һәм социал-демократик матбугат Финляндия турында легендалар, ялган әкиятләр чыгарды. Англия консерваторлары һәм лейбористлары, Америка демократлары һәм республиканецлары, һәр төрле социалистлар, Троцкий һәм башка ак эмигрантлар, король кисәкләре һәм президентлар, Рим папасы һәм барлык дин башлыклары, полицейскилар, шпионнар, урамнардагы һәм газета редакцияләрендәге фахишәләр—барсы да Советлар Союзына каршы, „бер нәрсәдә дә гаебе булмаган төньяк Аркадеяне“ саклау өчен „изге“ походка берләштеләр.

Барлык ярыклардан һәм капка асларыннан Советлар Союзының дошманнары килеп чыкты. Хәзерге заманның „алдынгы демократияләре“—Англия, Франция, Швеция, Швейцария һәм Кушма Штатлар Финляндияне яклау тавышы астында эшчеләр сыйнфы өстенә һәм беренче чиратта коммунистик партияләр өстенә ташландылар. Аңсыз да чикле булган ирекләр кысыла, эш көне озайтыла, хезмәт хакы киметелә һәм болар барсы да демократияне яклау исме астында үткәрелә. Ялган һәм яла ягу фабрикалары ходка җибәрелде. Үзләренең „объективизм“нары белән мактанучы телеграф агентлыклары һәм зур газеталар һич кеше ышанмаслык хыялый хәбәрләр, магнәсез уйдырмалар, оятсыз ялганнар сатучылар булып әверелделәр.

Бу хәлләрнең барсын да аңлау өчен, Советка каршы бара торган бу шау-шуның магнәсен төшенү өчен хәзерге вакытта Финляндия мәсьәләсе уңае белән безнең күз алдыбызда җәелеп бара торган барлык вакыйгаләрне якыннанрак карап белергә кирәк.

БОЛЬШЕВИКЛАР ҺӘМ ФИНЛЯНДИЯ

Октябрь революциясенә кадәр большевиклар Финляндиядәге эшчеләр хәрәкәте белән Россиядәге башка партияләргә караганда ныграк бәйләнгәннәр иде.

Гельсингфорста, Выборгда, Свеаборгда большевикларның эшчеләр оешмалары гына түгел, хәттә рус гаскәрләре арасында хәрби оешмалары бар иде. 1906 нчы елны Свеаборгда булган моряклар восстаниесе вактында Финляндиянең кызыл гвардиясе рус морякларына ярдәм итте.

Царизм вактында без фин эшчеләре ярдәме белән Финляндия аркылы әдәбият һәм корал чыгардык. Подпольедәге большевиклар, шул исәптән Ленин да, анда яшеренделәр. Революцион фин эшчеләре белән безнең элемтәбез нык иде.

Большевиклар царизмга каршы армый-талмый көрәшеп, Финляндиягә бәйсезлек таләп иттеләр. Большевиклар 1917 нче елны Финляндия мәсьәләсе буенча Милюковның һәм Керенскийның империалистик политикасына кискен рәвештә каршы чыктылар.

Февраль революциясеннән Октябрь революциясенә кадәрге чорда Выборгда, Гельсингфорста һәм Финляндиянең башка шәһәрләрендә урнашкан солдатлар һәм матрослар, Финляндия эшчеләре белән туганлык союзында булып, Керенский хөкүмәтенә каршы көрәштеләр, ә шул ук вакытта Финляндия буржуазиясе безнең революцион морякларыбызны бандитлар, уголовный җинаятчеләр һ. б. дип күрсәтеп, рус солдатларын һәм матросларын кыйнады.

1917 нче елның 31 нче декабрендә Финляндия вәкиле Свинхувуд Финляндиянең бәйсезлеге тулысынча танылу турында Лениннән карар алды.

Без, большевиклар, монардан барыннан да элек фин эксплоататорлары файдаланачакны белә торып, ни өчен соң Финляндиянең бәйсезлеген иглан итүгә бардык? 1917 нче елның 22 нче декабрендә Үзәк Башкарма Комитеты утырышында ясаган докладында иптәш Сталин моны болай дип аңлатып бирде:

„... Әгәр дә без Финляндиянең бәйсезлек яулап алуы күрнешенә игтибар беләнрәк карасак, барыннан да элек Халык Комиссарлары Советы үзе дә теләмәстән ирекне асылда Финляндиянең халкына, пролетариат вәкилләренә бирмичә, Финляндия буржуазиясенә биргәнлегенә ышанырбыз, бу соңгысы исә вакыйгаларнең гаҗәп бер үзгәреше аркасында бәйсезлекне Россия социалистлары кулыннан алды. Финляндия эшчеләре һәм социал-демократлары азатлыкны турыдан-туры социалистлар кулыннан алмыйча, фин буржуазиясе кулыннан алырга тиеш булып чыктылар һәм без моны фин пролетариатының трагедиясе дип карап, фин социал-демократларының үзләренә бәйсезлекне хөкем сөрүче буржуазия кулыннан тартып алу өчен кискен адым ясамаганлыклары бары тик аларның кыюсызлыклары һәм аңлашылмый торган куркаклыклары аркасында гына булганлыкны әйтми кала алмыйбыз.

Халык Комиссарлары Советын ачуланырга мөмкин, аңа тәнкыйт белән һәм бик начар карарга мөмкин, ләкин аны фразерлар дип, үзләренең вәгдәләрен үтәмәүчеләр дип атаучы бер кем дә юк, чөнки дөньяда Халык Комиссарлары Советын үзенең вәгдәләреннән баш тартырга мәҗбүр итәрлек көч юк. Без моны хәтта буржуазиянең дә үзенә бәйсезлек бирү турындагы таләпләренә бөтенләй риясыз каравыбыз белән һәм шунда ук Финляндиянең мостәкыйллеге турындагы декретны чыгарырга керешүебез белән исбат иттек. Финляндиянең азатлыгы ахыр чиктә Финляндиянең эшчеләренә һәм крестьяннәренә тулы бәйсезлек бирсен һәм халыкларның мәңгелек дуслыгы өчен нык нигез тудырсын“.

(„Известия Центрального Исполнительного Комитета и Петроградского Совета рабочих и солдатских депутатов“, № 260, 24 декабрь, 1917 г.).

Ахыр чиккә кадәр китереп җиткерелгән Финляндия пролетарийлары 1918 нче елны буржуазиягә каршы восстание күтәрделәр. Маннергейм палачлары тарафыннан үтерелгән ун меңнәрчә эшчеләр һәм крестьяннар арасында күп кенә рус эшчеләре, революцион моряклар һәм солдатлар бар. Рус һәм фин халыклары улларының каны бергә кушылды һәм бу кан белән СССР һәм Финляндия халыклары арасындагы элемтә беркетелде һәм нығытылды.

Большевиклар Финляндиянең бәйсезлеге өчен көрәшкәндә, Ленин аның вәкилләренә бәйсезлек турындагы актны тапшырганда, Финляндиядә эш башында эшчеләр сыйнфының иң явыз дошманнары—свинхувуд әфәнделәр һәм компаниясе торганлыкны большевиклар белделәр, ләкин без үз программабызны—милләтләрнең үз билгеләнүләре, хәтта бөтенләй аерылып чыгулары хокукын нык итеп тормышка ашырдык. Без моны эшләгәндә Финляндия Советка каршы интригалар һәм заговорлар плацдармына әверелмәс дип уйлаган идек. Ләкин Финляндия Советка каршы махинацияләр мәйданына әйләнеп китте.

АК ФИНЛЯНДИЯ—СССР ГА КАРШЫ СУГЫШ ПЛАЦДАРМЫ

Финляндияне СССР га каршы сугыш плацдармына әйләндерү 1919—1939 нчы елларда төрле юллар белән алып барылды.

Англия, Франция, АКШ һәм Швеция Финляндия промышленностена шактый күп капитал салдылар һәм Финляндия экономик яктан Англия—Америка капиталына буйсындырылды. Шушы „дуслар“ ярдәме белән Финляндия системалы рәвештә коралланып килде: оборона линияләре (чынлыкта—һөҗүм итү линияләре) корылды, Финляндиягә кирәк булганнан уннарча тапкыр артып китә торган күләмнәрдә аэродромнар, төшү площадкалары ясалды. Финляндия Советка каршы лагерга әйләндерелде.

1924 нче елны Финляндиягә генерал Кирк җитәкчелегендә Англиянең хәрби комиссиясе килде. Хельсинкидан кайту белән 1925 нче елның 1 нче апрелендә Кирк Лондондагы хәрби-фәнни җәмгыяттә ясаган докладында үзенең фикерләрен хәрби-политик яктан нигезләде. Кирк барыннан да элек Аланд атауларында Англиянең хәрби-диңгез базаларын төзергә кирәклекне күрсәтте һәм әгәр дә Россия Финляндиядә хәрби-диңгез базалары ясарга дәгва итсә, ул чагында „ихтимал, кемнең булса да башка берәүнең моңа тоткарлык ясавы шул кадәр үк әһәмиятле булачак“ диде һәм шуңа күрә дә әгәр дә Финляндиягә һөҗүм ясалса, аның озак вакытлар буена бер үзе калуы чынлыкта һич ихтимал түгел“ дип өстәде.

1925 нче елның апрелендә һава флотын киңәйтү теләге белән һава флотын оештыру буенча Англия инструкторы Финляндиягә килде. Шуның өстенә Финляндия хөкүмәте Англиянең тагын берничә инструкторларын, беренче чиратта техник гаскәрләр буенча һәм флот буенча инструкторларны чакырды.

1925 нче елның 16 нчы июнендә Финляндиягә адмирал Келли җитәкчелегендә 14 карабтан гыйбарәт булган Англия флоты килүне дә шушы комиссиянең эше тәмам булу уңае белән булган дип карарга кирәк.

Ул чагында фин газеталары „Англия дуслыгы“ турында бик күп шауладылар. Генерал Кирк 1939 нчы елның апрелендә Финляндиягә тагын килде һәм Финляндиянең оборонасы оештырылуына чиктән тыш сокланды.

Финляндияне Советка каршы файдалану өчен хәрби лагерга әйләндерергә кирәк иде. Тиешле милли психоз тудырырга кирәк иде. Шуннан шюцкорлар оешмаларының төзелүе һәм үсүе килеп чыкты, алар бик яхшы коралландырылдылар һәм өйрәтелделәр; шуннан Финляндиядә ярым бандит милләтчеләр оешмалары төзелде, алар „бөек Финляндия“ төзү турында, СССР дан Карелияне генә түгел, бәлки „кардәш кабиләләр“ урнашкан, ягни Уралга кадәр булган барлык территорияләрне тартып алырга кирәклек турында көн саен акырындылар; илнең эчке һәм тышкы политикасын берләштерү теләге белән Финляндиянең һәм Англиянең җитәкче эшлекләләре арасында даими аралашу урнаштырылды, күп кенә провокацияләр оештырылды.

Шулай итеп Ленинградның янында гына Советлар Союзының явыз дошманнарының оясы корылды һәм Финляндияне СССР га каршы файдалану өчен сугыш-техника шартлары һәм материаль шартлар тудырылды.

Әгәр без чикләребездәге шушы эшләрне күрмәгән булсак һәм Советка каршы машинаны ходка җибәрү өчен дошманнарыбызның уңайлы момент кына көтеп торуларын аңламаган булсак без большевиклар дигән бөек исемгә лаеклы булмаган булыр идек.

АНГЛИЯ—ФРАНЦИЯ БЛОГЫНЫҢ ИСӘБЕНДӘ ЯЛГЫШУЫ

Европада дары исе аңкый башлагач Англиядәге һәм Франциядәге сугыш уты кабызучылар, барсына да гарантияләр биреп, үзләренең интересларын саклый алырлык армия эзли башладылар. Англичаннар читләр каны белән яңа позицияләр яулап алырга һәм иске позицияләрне саклап калырга күнеккәннәр һәм алар, Кызыл Армиянең көчләреннән файдаланырга теләк белдерү белән үк Совет хөкүмәте „баш өсте“ дип җавап бирер дип уйладылар.

Ләкин бу нәрсә Лондонда һәм Парижда уйлаган кебек барып чыкмады. СССР—патша Россиясе түгел. Безнең үз максатларыбыз һәм үз бурычларыбыз бар. Англия—Франция империалистларының СССР ны үзләренең реакцион максатлары өчен файдаланырга маташулары, маглүм ки, җимерелү белән тәмам булды.

СССР белән Германия арасында һөҗүм итешмәү турында пакт төзелү, ә аннары дуслык турында договор төзелү, Көнбатыш Украинаны һәм Көнбатыш Белоруссияне поляк паннарыннан азат итү англичаннарны — французларны һәм аларны яклаучы американнарны котырыну хәленә китереп җиткерде, чөнки алар алдау яки томанлы вәгдәләр бирү юлы белән большевиклардан файдаланырга мөмкин түгеллеккә ышандылар.

СССР белән Эстония, Латвия һәм Литва арасында үзара ярдәмләшү турында төзелгән договорлар да СССР га каршы котырынган агитация өчен сылтау булып хезмәт иттеләр. Шуның белән бергә, бөтен агитация Балтыйк буе советлаштырылачак дигән ялганга нигезләнгән иде. Шул уңай белән империалист әфәнделәр шундый коточкыч нәрсәләр китереп чыгардылар ки, хәтта үзләре дә курка башладылар.

Бу кампаниянең теләге Эстониянең, Латвиянең һәм Литваның эре буржуазиясендә генә түгел, бәлки урта һәм вак буржуазиядә дә дуслык турындагы договорга каршылык китереп чыгару, Совет экспансиясе, Көнчыгыш Европаның һәм Советлар Союзы белән чиктәш булган барлык илләрнең советлашуы белән Германияне куркыту һәм Германия белән СССР арасын бозарга маташу иде.

Ленинградка куркынычсызлык тәэмин итү турындагы мәсьәлә буенча СССР белән Финляндия хөкүмәте арасындагы сөйләшүләр Советка каршы котырынып яла ягуны һәм урынсыз гаепләр ташлауны китереп чыгардылар. Англия, Франция, Америка финнәрне бер нинди дә ташламага бармаска ачыктан-ачык котырттылар. СССР белән сөйләшүләр вактында Финляндия Кушма Штатлардан җиңел генә һәм тиз генә 10.000.000 доллар заем алды. Англия финнәргә теләгән кадәр корал вәгдә итте; Швециянең элекке чит ил эшләре министре Сандлер финнәргә сугыш ярдәме вәгдә итте; французлар, норвегиялеләр һәм итальяннар аларга мораль теләктәшлек һәм материаль ярдәм вәгдә иттеләр. Шушы котыртулар һәм вәгдәләр йогынтысы астында эркколар, каяндерлар һәм таннерлар Советлар Союзы ясаган тәкдимнәргә риза булудан баш тарттылар.

Эркко—Каяндер—Таннер хөкүмәте Советлар Союзының тәкдимнәреннән баш тартып кына калмады, бәлки фин ак бандитлары Совет чигендә провокацияләр кора башладылар һәм бу хәл Англия—Франция империалистларының һәм аларның Финляндиядәге иярченнәренең чын уйларын шунда ук ачып салды.

Совет хөкүмәте һөҗүм итешмәү турындагы пакттан баш тартуын белдерде һәм демократик Отто Куусинен хөкүмәте белән үзара ярдәмләшү һәм дуслык турында договор төзеде. Куусинен хөкүмәтенең һәм аның белән дуслык турындагы договорның төзелүе Советка каршы шундый котырыну дулкыны тудырды ки, аны бары тик Октябрь революциясеннән соң булган котырыну белән генә чагыштырырга мөмкин. Медицинада „делириум тременс“ (белая горячка) дип атала торган нәрсә башланды. СССР белән Англия, Франция, Кушма Штатлар һәм башка капиталистик илләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә яңа чор башланды, бөтен дөнья тарихының яңа сәхифәсе башланды.

МАННЕРГЕЙМ—РЮТИ—ТАННЕР ЛИНИЯСЕ

Беренче бәрелешләр үк инде фин буржуазиясенең Финляндия өчен гаять зур булган армия төзегәнлеген, империалистик державалар ярдәме белән көчле нығытмалар ясаганлыгын һәм шактый күп хәзерге заман кораллары запасы җыйганлыгын күрсәтте. Буржуаз газеталар Финляндиянең нығытмалар линиясен Мажино линиясе дип, Зигфрид линиясе дип яки Маннергейм линиясе дип атыйлар. Бу нығытмалар линиясе нинди соң? Бу нығытмалар турында Американың бер журналы түбәндәгечә яза:

Финляндиядә нығытмалар төзү төп өч районда: Карелия бугазында, Хельсинки районында һәм Або районында алып барылды. Хельсинки һәм Або районнарында яр буе батареяләре куелган һәм алар бу пунктларга диңгездән керү юлын саклыйлар.

Карелия бугазында Фин заливыннан Ладога күленә кадәр ике рәтле нығытмалар һәм Выборг районында каршылык күрсәтү узелы төзелгән.

Беренче оборона полосасы СССР чиге янында ук урнашкан, аның киңлеге 5—12 километр. Андагы нығытмалар системасы аз сандагы озак вакытлы корылмалардан, фортификация кыр корылмалары—блиндажлары, окоплары, йөрү юллары, тимерчыбык корылмалары һәм канаулар, чокырлар, миналар һ. б. төсендә танкка каршы тоткарлыклары булган 38 ләп озак вакытлы ут точкаларыннан (ДОТ) гыйбарәт.

Оборона нығытмаларының икенче полосасы аеруча көчле һәм ул—каршылык күрсәтүнең төп линиясе. Аның озак вакытлы ут точкалары 2—10 километр киңлектә булып, бу нығытмалар полосасы фин заливыннан Ремпетти, Сумма, Лейпясуо станциясе, Муола, Мялкеля, Виркки, Кивиниеми һәм башка пунктлар аркылы сузыла һәм аннары Сувантоярви күленең төньяк яры буйлап Ладога күле буендагы Тайпале крепостена кадәр җитә.

Бу нығытылган чиктә барлыгы 150 ләп озак вакытлы ут точкалары һәм 100 ләп агачтан һәм балчыктан ясалган ут точкалары бар. Аларның күпчелеге пулемет өчен ясалган. ДОТ лар тимерчыбык корылмалары белән һәм канаулар, эскарплар, таштан ясалган тәбәнәк баганалар һ. б. төсендәге танкка каршы корылмалар белән чолгап алынган.

Выборг районында каршылык күрсәтү узелы Сяйние станциясе—Алясяйние авылы районында коры жир нығытмаларыннан һәм Выборгда һава һөҗүме оборонасы булган яр буе нығытмаларыннан тора: Сяйние станциясе—Алясяйние авылы районындагы нығытмалар эченә 8 ДОТ һәм кыр фортификация корылмалары керә.

Озак вакытлы ут точкаларының (ДОТ ларның) күпчелеге—пулеметлар өчен тимер-бетоннан ясалган ярым капонирлар һәм капонирлар. Аларның саклану түбәләренең һәм стеналарының калынлыгы 0,8—1,2 метрга җитә. Стеналары бер ярым метрга җитә торган яки бронядан ясалган ДОТ лар да очрый.

Күлләрнең һәм урманнарның күп булуы финнәргә Карелия бугазында ныклы оборона булдырырга шактый ярдәм иткән.

Карелия бугазын нығыту буенча 1922 нче елны башланган эшләр 1939 нчы елга инде нигездә тәмам булган. 1939 нчы елны финнәрнең төп тырышлыклары ясалма тоткарлыклар, бигрәк тә танкка каршы тоткарлыклар төзүгә юнәлдерелгән булган. Моның өчен тирән чокырлар казылган, юлларга миналар салынган, җиргә гаять зур таш кисәкләре күмелгән һ. б.

Карелия бугазында нығытмалар оештыруда турыдан-туры катнашкан Белгия генералы Эмиль Баду, 1940 нчы елның башында Финляндиядән Брюссельгә кайткач, „Суар“ газетасының хәрби күзәтүчесенә болай дип белдергән:

„Маннергейм линиясендә төзелгән хәзерге заман тиһындагы качу урыннарында финнәрнең күзәтче-солдатларына һичбер куркыныч юк. Ул күренми, үзе исә снарядлар тия алмаслык ярыктан атып ята. Эре калиберлы ике пулемет, күршедәге нығытмаларның орудиеләре белән берлектә, дошманга флангдан ата алалар. Маннергейм линиясенең барлык нығытмалары тимерчыбык корылмалары белән чолгап алынган“.

Бая әйткәнебезчә, 1939 нчы елның маенда һәм июнендә Финляндия нығытмаларын Англия армиясе генералы Кирк караган. Шул ук елның августында бу нығытмаларны Швециянең сугыш министре Шельд караган. Чит ил вәкилләренең бу визитлары Финляндия нығытмаларының кем ярдәме белән һәм кем җитәкчелегендә төзелгәнлеген күрсәтәләр.

Финляндиянең сугыш көче нинди? Дөрес саннарга караганда, Финляндия, шюцкорчыларны кушып исәпләгәндә, 500 мең кеше туплаган. Бу—7 кешегә бер солдат дигән сүз. Бу процентның нинди зур икәнлеген түбәндәге чагыштырма ачык күрсәтә: әгәр СССР шушы процент буенча армия туплаган булса иде, бездә армия 25 миллион кешедән торган булыр иде.

Фин гаскәрләре техника ягыннан яхшы өйрәтелгәннәр һәм коралландырылганнар, ләкин шулай ук алар шюцкорлар оешмалары тарафыннан политик яктан да бик нык кулга алынганнар. Бу оешма сайлап алынган ак гвардеецлардан тора.

Нәрсә ул шюцкор? Шюцкор—буржуазиянең коралланган ирекле оешмасы. Ул, сыйнфи көрәш кискенләшкән чорда революциягә каршы юнәлдерелгән көч сыйфатында килеп чыкты. Революцион хәрәкәткә каршы көрәштән тыш шюцкорга илнең оборонасын нығыту бурычы да йөкләнгән. Шуның белән бергә армиянең территориаль системага күчүе уңае белән шюцкорның бу бурычы шактый киңәйтелгән. Революцион хәрәкәткә каршы көрәштә полициянең көче җитмәгән барлык хәлләрдә шюцкор аңа ярдәм күрсәтә.

Шюцкор Финляндиянең элекке хөкүмәтеннән зур ярдәм алып торды. Бу оешмага дәүләт бюджетыннан миллионнарча марка расход тотылды.

Шюцкорның культура-агарту эше шәһәрнең һәм авылның вак буржуазиясе арасында шовинистик настроениеләр кабызуга юнәлдерелгән. Ул оештыра торган пропаганданың максаты—халыкта бөтен революцион нәрсәгә һәм бигрәк тә СССР га карата дошманлык тудыру, „бөек Финляндия“ идеясен популярләштерү.

Бу пропагандага турыдан-туры шюцкорның баш штабының махсус бюросы җитәкчелек итә. Урыннарда исә аңа аеруча реакцион элементлар—поплар һәм башкалар җитәкчелек итәләр.

Шюцкор 17 яшькә кадәр булган яшьләрне хәзерләүгә аеруча игтибар бирә. Шюцкор янында „яшьләр бүлекләре“ дигән бүлекләр бар. Бу бүлекләр 30 меңнән артык яшьләрне берләштерәләр. Хатын-кызлар арасындагы эшне шюцкорның хатын-кызлар оешмасы „Лотта-Свярд“ алып бара. Ул, сугыш вактында тылга хезмәт күрсәтү өчен кирәкле кадрлар хәзерли. Шюцкор сафларында барлыгы 200 мең чамасы кеше бар.

Салкын кыш, кар бураннары, Финляндиянең табигый шартлары, һич шиксез, ак финнәргә үзләренең котылгысыз һәлакәтләрен кыска гына срокка кичектереп торырга ярдәм иттеләр һәм шушы уңай белән финнәр үзләренең ялган җиңүләре турында көн саен мактанулы белдерүләр чыгаралар.

СКАНДИНАВИЯ ИЛЛӘРЕ ҺӘМ АК ФИНЛЯНДИЯ

Читләр кулы белән табыш тупларга күнеккән англичаннар һәм французлар СССР га каршы сугышка Швецияне һәм Норвегияне тарту өчен Швеция һәм Норвегия буржуазиясенең фин буржуазиясе белән бергәләп эш итүеннән файдаланырга маташалар. Шул ук сугыш уты кабызучылар Финляндияне котыртып, хәзер Швецияне һәм Норвегияне провокациягә тартырга маташалар һәм аларга, билгеле, һәр төрле ярдәм вәгдә итәләр. (Заманында Польшага күрсәтелгән ярдәм кебек түгелме икән?).

Швециянең элекке чит ил эшләре министре Сандлер Финляндия хөкүмәтен СССР куйган шартларга риза булмаска мәҗбүр итү өчен күп тырышты. Сандлер финнәргә Швециянең сугыш ярдәмен вәгдә итте, ә финнәр бу вәгдәләрне үтәүне таләп итә башлагач, Швеция буржуазиясе никадәр генә сугышчан булса да, Сандлерга отставка бирергә һәм бу социал-демократ сугыш чукмарын архивка тапшырырга мәҗбүр булды. Хәзер Сандлер һәм элекке коммунист, хәзерге ренегат Хеглунд Швеция социал-демократиясенең активистлар канатына җитәкчелек итәләр һәм СССР га каршы котырынып кампания алып бару һәм интервенцияне яклап агитация алып бару өчен бу партиянең үзәк органы „Социалдемократен“нан файдаланалар.

Норвегиядә дә буржуазиянең югарыгы катлавы һәм социал-демократия ак финнәргә һәр төрле ярдәм һәм булышлык күрсәтүне яклый. Монда да рәсми кешеләр һәм хөкүмәткә якын тора торган даирәләр СССР га каршы кампаниядә актив катнашалар.

Нак әнә шул уңай белән Совет хөкүмәте 5 нче һәм 6 нчы январьда Швеция һәм Норвегия хөкүмәтләренә ноталар тапшырган иде. Белдерүләрнең берсендә әйтелгәнчә, әгәр Швеция Советлар Союзы белән сугыш хәлендә булса, яки СССР га каршы сугышка хәзерләнсә бу кампанияне акларга мөмкин булыр иде.

Швеция һәм Норвегия хөкүмәтләренең җаваплары һич тә канәгатләнерлек булмады. Үзләренең нейтралитетлары турында белдереп, Швеция һәм Норвегия хөкүмәтләре бөтен кампанияне бу илләрдә матбугат ирке белән аңлатырга маташалар. Без капиталистик илләрдә матбугат иркенең нинди икәнлеген беләбез һәм безне бу сылтаулар ышандыра алмаслар. Швеция хөкүмәтенең дә, Норвегия хөкүмәтенең дә доброволецлар туплауда, корал сатуда, корал үткәрүдә һәм СССР га каршы булган бөтен агитациядә бер нинди катнашлары юк, имеш. Бу җаваплар икесе дә „минем ат түгел, мин хуҗа түгел“ дигән принципка нигезләнгәннәр. Билгеле, Совет хөкүмәте мондый җавапларны канәгатләнерлек дип таба алмады. Тик шул гына ачык: Совет хөкүмәтенең Швециягә һәм Норвегиягә биргән ноталары Швецияне СССР га каршы сугышка тартырга теләүче державаларга җитәрлек каршылык күрсәтмәүчеләргә карата җидди кисәтү булып торалар.

Швеция хөкүмәте заем алу һәм кораллар сатып алу өчен АКШ ка махсус миссия җибәрде. Бу заем һәм кораллар белән Швеция хөкүмәте ак финнәр өчен Швециядән кораллар җибәрү уңае белән Швециянең коралланыуында һәм бюджетында килеп чыккан бушлыкны тутырырга тели. Хәзер Швециядә көрәш кискенләште. Активистлар хәзер үк сугышта катнашуны таләп итәләр, хөкүмәт бу авантюраның Швеция өчен бик куркынычлы икәнлеген аңлап моңа каршы килә.

(ДӘВАМЫ КИЛӘСЕ НОМЕРДА).

РОКК ОЕШМАЛАРЫ ҺӘМ АЛАРГА ҖИТӘКЧЕЛЕК

Фронтка булышуда, шулай ук тылны дошман һөҗүменнән саклау эшендә массовый-оборона оешмалары зур роль уйныйлар. Советлар Союзының массовый-оборона оешмалары, шул исәптән РОКК оешмалары, массовый санитария-оборона кадрлары хәзерләү юлы белән бөек Ватаныбызның оборона сәләтен һәр яклап ныгытырга, данлыклы Кызыл Армиябез өчен һәр яктан хәзерлекле запас кадрлар хәзерләргә чакырылганнар.

Бездә массовый-оборона оешмаларының, шул исәптән РОКК оешмаларының эшендә актив катнашучылар миллионлап санала. Алар оборона значокларына нормалар тапшыралар, производстводан аерылмыйча укып, хәрби һөнәрләрне үзләштерәләр. Хасан күле районында япон самурайларын тар-мар иткән көннәрдә, Халхин-Гол елгасы буендагы сугышларда, Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия хезмәт ияләрен поляк паннары изүеннән азат итү походында оборона активистлары, аерым алганда РОКК хәзерләгән активистлар—медицина сестралары, сандружина членнары Ленин—Сталин партиясе эшенә чын күңелдән бирелгәнлекнең югары үрнәкләрен күрсәттеләр. Хәзер алар ак финнәргә каршы сугыш фронтларында шундый ук үрнәкләрне күрсәтәләр. РОКК оешмалары хезмәт ияләре арасында, допризывниклар һәм призывниклар арасында зур эш алып баралар.

РОКК ның Татарстан оешмалары партиянең XVIII нче съездыннан соң, үзләренең эшләрен шактый яхшырттылар һәм уңышлы нәтиҗәләргә ирештеләр. РОКК оешмалары сан ягыннан үсте һәм аларның эш сыйфаты да яхшырды. 1939 нчы елны РОКК сафларына 24.028 кеше член итеп алынды. Хәзер безнең республикабызда 52.940 кеше РОКК члены булып тора. 1939 нчы елны янадан 771 башлангыч оешма төзелде. Кызыл Армиягә запас медицина сестралары хәзерләү буенча РОКК ның Татарстан Өлкә Комитеты 14 группадан гыйбарәт булган курслар оештырды. Аларда производстводан аерылмыйча хезмәт иясе хатын-кызлардан 420 кеше укый.

ВКП(б) райкомнары һәм аларның хәрби бүлекләре ярдәме белән предприятиеләрдә 11 урында хәрби-санитария дружиналары оештырылды.

РОКК оешмалары үткән елны 19 мең кешене ГСО значкистлары итеп хәзерләделәр. Санитария-оборона эше мәктәпләрдә дә киң җәелдерелде. Пионерлардан һәм башка укучы балалардан 8 мең кеше БГСО значогына нормалар тапшырды.

Бу—гаять зур армия. Алар Кызыл Армия сугышчыларына ярдәм итәргә һәр вакыт хәзер торалар. Ак финнәрнең провокацион чыгышларына җавап итеп, Кызыл Армиябез чикне үтеп чыккач та, оборона активистларыннан фронтка җибәрүне, Кызыл Армия сугышчыларына санитария ярдәме күрсәтү өчен үзләрен госпитальләргә урнаштыруны сорап язылган йөзләрчә һәм меңнәрчә гаризалар алынды. Икенче баскыч ГСО значкистлары Галеева һәм Алексеева иптәшләр РОКК ның Өлкә Комитеты Президиумына килеп: „Без шоферлар, безне фронтка җибәрегез, без танк частьләрендә эшләрбез" дип белдерделәр. Ленин—Сталин партиясе эшенә ахрынача бирелгән мондый патриотлар РОКК сафларында бик күп. Бу армияне тагын да үстерергә кирәк. Бүгенге шартлар бездән моны нык таләп итә.

Әйтергә кирәк, РОКК оешмаларының эшендә зур гына җитешсезлекләр дә бар әле. Кайбер предприятиеләрнең партия, комсомол һәм профсоюз оешмаларының җитәкчеләре урыннарда РОКК оешмаларының эшенә җитәрлек игтибар бирмиләр. РОКК ның Өлкә Комитеты тарафыннан оештырылган курсларның эшенә җитәкчелек итмиләр. Район оешмалары тарафыннан җитәкчелек булмаган урыннарда курсларның эше аеруча начар тора. Ленин районында (Казан) оештырылган курсларның әле һаман да ныклап эшкә керешмәүләре моны ачык күрсәтәләр. Сталин районында өч урында курслар оештырылды. Ләкин ВКП(б) ның район комитеты бюросы бу курсларда эшнең торышы турындагы мәсьәләне үзенең утырышларында бер генә тапкыр да тикшергәне юк. Райком курсантлар арасында политик-тәрбия эшенең куелышы белән кызыксынмый. Юридик институт янында оештырылган курсларда да шундый ук хәл. Аларның эшенә администрация һәм партоешма тарафыннан җитәкчелек канәгатьләнерлек түгел. Күп кенә авылларда да санитария-оборона эшенең куелышы тиешле югарылыкта тормый әле.

Кызыл Армиягә, Хәрби Диңгез Флотына һәм хезмәт ияләренә санитария хезмәте күрсәтергә сәләтле булган кадрлар хәзерләү өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар. Алардан тулысынча файдаланырга гына кирәк.

ВКП(б) һәм ВЛКСМ райкомнары, шулай ук район Советларының башкарма комитетлары РОКК ның башлангыч оешмаларына конкрет ярдәм итәргә, аларны ныгыту буенча эшне тагын да көчәйтергә тиешләр.

Г. Камалеттинов.

РОКК ның Татарстан Өлкә Комитеты Президиумы председателе.



Яш белгечләрдән—Казан Дәүләт университетын тәмам итүчеләрдән (сулдан) И. К. Герасимов, Г. Ф. Абдульманов һәм П. Н. Сорокин иптәшләр. Алар Ерак Көнчыгышка эшкә китәләр. А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

ГРАЖДАННАР СУГЫШЫ ЭЗЕННӘН ПОХОД

„Большевик" спорт җәмгыятенең чаңгычы физкультурникларыннан 50 кеше (шуларның 18 е хатын-кызлар) Кызыл Армия һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгына багышлап кызыклы поход үткәрделәр. Алар Казан—Зөя—Казан маршруты белән походка чыгып, Казан, Зөя һәм аның тирәләрендә гражданнар сугышыннан калган памятниклар белән таныштылар.

Походчылар (командиры һәм экскурсоводы иптәш Разумовский) Зөядән ерак түгел урында күмелгән большевик—командир Ян Юдин каберен карадылар. Зөядә алар „Коммунарлар стенасы" белән таныштылар. 1918 нче елның 7 нче сентябрендә чех-словаклар Зөянең Эшче-Крестьян һәм Солдат Депутатлары Советы членнарын һәм V нче армия җитәкчеләрен әнә шул „Коммунарлар стенасы" урнашкан мәйданда атканнар.

Зөядән Казанга кайтышлый Моркваш янында походчылар гражданнар сугышы елларында Волга флотилиясе торган урыннарда булдылар. Гражданнар сугышы елларында казылган окопларны карадылар.

Походчылар Зөядәге туристлар базасында „1918 нче елны Казанны һәм Зөяне чех-словаклардан азат итү" дигән темада лекция тыңладылар. Походта 14 допризывник катнашты.

Композитор Шопен иҗадына багышланган кичә

Казан Музыка училищесе 29 нчы февральдә бөек композитор Шопенның туууына 130 ел тулу уңае белән музыкаль кичә үткәрә. Кичәдә композиторның тормышы һәм иҗады турында доклад куела.

Соңыннан училище укучылары көче белән Шопен әсәрләреннән төзелгән концерт бирeләчәк. Шул ук программа белән шәһәрдә дә бер ачык концерт бирергә уйланыла.

СӘҮДӘ ЧЕЛТӘРЕ ҮСӘ

Узган ел Татарстанның авыл районнарында потребкооперация тарафыннан ачылган 52 раймаг, 390 сельмаг, 3.689 кибет, ларек һәм башка сәүдә точкалары эшләде. Быел сәүдә челтәре тагын да киңәя. Яңадан 160 сельмаг, 108 кибет, ларек һәм башка сәүдә точкалары ачылачак.

Язгы чәчү вакытында колхоз станнарында 262 ларек ачыла, 498 урында ат белән, 921 урында лотоктан сату оештырыла, 439 колхозда китап һәм газета-журнал сату оештырыла.

Тарханда, Биектауда, Кузнечихада, Столбищеда һәм Юдинода яңа раймаглар ачыла.

Каюм Насыйриның паспорты

Казан Дәүләт Педагогия институты студенты Фатыйх Вәселев Татарстанның Тел-Әдәбият Фәнни-Тикшерү институтына Каюм Насыйриның паспортын тапшырды. Бу паспорт 1197 нче номерлы булып, 1888 нче ел, 22 нче июньдә Шырдан волостной старшинасы тарафыннан бирелгән. Паспортта Каюм Насыйриның туган елы күрсәтелмичә аның 69 яштә булуы һәм чыгышы крестьян икәнлеге язылган. Паспортның 16 нчы битендә Каюм Насыйриның Поперечная Сенная урамында Хөсәенев йортында торуы турында 1902 нче елның 2 нче апрелендә Казан шәһәренең 2 нче частенең билгесе куелган. Беренче битендә кем тарафыннандыр татарча: „Каюм Насыйров туган 1825 нче сәнәдә, вафат 1902 нче сәнәдә. 77 нче яшендә буладыр" дип язылган.

Каюм Насыйриның туган һәм үлгән елын дөрес билгеләү өчен бу документның зур әһәмияте бар.

КУСТАРЬЛАРНЫ ЯЛ ЙОРТЛАРЫНА ҖИБӘРҮГӘ 736 МЕҢ СУМ

Промкооперация артельләрендә эшләүчеләрне ял йортларына һәм курортларга җибәрү өчен ел саен күп кенә акча тотыла.

1939 нчы елда Татпромстрахкасса кустарьлардан 1.803 кешене ял йортларына, 274 кешене курортларга һәм санаторийларга җибәрде. Шулардан 112 кеше ерак курортларда дәваланды. Бер көнлек ял йортына 1.989 кеше җибәрелде.

Быел ял йортларына 2.200 кеше, курорт һәм санаторийларга 325 кеше, бер көнлек ял йортына 1.870 кеше җибәреләчәк. Бу эшләргә 736 мең сум акча билгеләнде.

Пропагандистларның республика семинары

Казанның Партия Мәгарифе йорты, пропагандистларның республика күләмендә чираттагы семинарын чакырырга хәзерләнә. Семинарга Татарстанның барлык районнарыннан да пропагандистлар киләчәк.

Партия Мәгарифе йортының лекторлары аларга „ВКП(б) тарихының кыскача курс"ының X, XI һәм XII нче бүлекләреннән лекцияләр укыячаклар.

Семинар 19 нчы мартта җыела һәм 5 көн дәвам итәчәк.

ШАХМАТ ЧЕМПИОНАТЫ

ТУРНИРНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЯРТЫСЫ ЙОМГАГЫ

Гомуми ял көннәрендә һәм алтыкөнлекнең икенче көннәрендә Казанның шахмат-шашка клубы шахматчылар, шахматны яратучылар белән тулы була. Шахмат буенча Казан беренчелеге өчен бара торган көрәшне алар зур кызыксыну белән күзәтәләр.

26 нчы февральдә турнирның 6 нчы туры булды һәм шуның белән турнирның беренче яртысы тәмам булды. Турнирда хәзер бер яктан чын-чынлап алдан баручылар (лидерлар) һәм, икенче яктан, уңышсыз уйнаучылар—артка калучылар барлыкка килде.

Лидерларның иң уңышлысы итеп яш тимер юлчы иптәш Сайгинны алырга кирәк. Турнирны ул зур күтәренкелек белән алып бара һәм 6 тур барышында аның әле бер партия дә оттырганы юк. 4 нче турда аның Ермолин белән уйнарга тиешле партиясе уйналмый калды, 5 нче турда ул Нотариус белән ничья ясады һәм 6 нчы турда аның берәү белән дә очрашуы булмады. Турнирның беренче яртысында ул мөмкин булган 4 очкодан 3½ очко җыеп, беренче урынны хәзергә үз кулында тота.

СССР ның шахмат мастерлыгына кандидат иптәш Нәҗметтинев турнирның үзәк фигурасы санала. Катнашучыларның һәрберсе аның белән очрашуга бөтен көчен куя һәм, әйтергә кирәк, бер үк вакытта шашка чемпионатында да беренчелек өчен көрәш алып баручы студент Нәҗметтиневкә шахмат чемпионаты шактый авырга килә һәм ара-тирә аңа көтелмәгәндә сюрпризлар да китерә. Нәҗметтинев турнирның башында ук Хенкин белән ничья ясады, аннары рәттән ике партияне откannan соң, ул 4 нче турда Колчурингa каршы аклар белән уйнап, партияне гаять яхшы алып барды, һәм отышлы позициягә иреште. Ләкин, хәл итүче моментта ул үзенең атакасы белән мавыгып, бер йөрешне вакытсыз ясады һәм нәтиҗәдә партияне оттырырга мәҗбүр булды. 5 нче турда Вельтмандерга каршы партиясендә ул инде бернинди өстенлек тә ала алмады, хәтта бер вакытны аның хәленә „оттырышлы" дигән бәя дә бирелде. Бөтен игтибарны туплап, зур осталык белән саклануы нәтиҗәсендә, бу партия Нәҗметтиневнең бер пешкасы артык хәлдә кичектерелде. 6 нчы турда Нәҗметтинев үзенең искиткеч атака стилен күрсәтте. „Буревестник" вәкиле Ермолин аңарга бер төрле каршылык та күрсәтә алмады. Катнашучыларның берсенең әйтүенчә Ермолингa, чыннан да „тын алырга да ирек булмады". Нәҗметтинев аның король флангысына җимергеч атака алып барды, соныннан бу атаканы бик оста итеп ферзь флангысына күчерде һәм үзенең филе (слоны) белән ладьясен биреп, каршы якны бирелергә мәҗбүр итте. Нәҗметтиневнең хәзер 5 партиядән 3½ очкосы бар һәм ул әлегә Сайгиннан шактый артта калып бара.

Казанның күренекле шахматчысы Колчурин тур саен диярлек уңышсызлыкка очрый. Очраклы рәвештә Нәҗметтиневне оту да аңа тиешле күтәренкелекне китерә алмады. 5 нче турда аның Кильматов белән булган партиясе хәзергә билгесез хәлдә кичектерелде, ә 6 нчы турда ул Хенкин белән очрашып, чираттагы җиңелүгә очрады. Карт шахматчы Косолапов та турнирны тигез дәрәҗәдә алып бара алмый. Турнирда катнашучы яшьләр гаять нык каршылык күрсәтәләр. 4 нче турда Косолапов Вельтмандерга бирелергә мәҗбүр булды. 5 нче турда—Ермолин белән ничья ясауга иреште һәм тик 6 нчы турда гына Нотариусны ота алды.

Турнирда көрәш зур кискенлек белән дәвам итә. Киләсе, 7 нче тур 1 нче мартта булачак.

Г. Х.

ТАТАРСТАНДА

■ Икмәк пешерү работниклары профсоюзының өлкә комитеты Биектау районының Казан лесхозы урманында пионерлар өчен лагерь оештыра. Лагерьда тору урыннары, ашханә һәм башка биналар салу өчен 3,2 гектар урман мәйданы бирелә.

■ Татарстан Азык Промышленносте Халык Комиссариатының предприятиеләренә капитальный ремонт ясау өчен 1940 нчы елга 495 мең сум акча билгеләнде. Лаештагы саго заводына, Казандагы мальтоза заводына һәм Чүпрәле районында яшелчә киптерү заводына реконструкция ясалачак.

■ Татарстан колхозларында умарта белгечләре хәзерләү һәм умартачылык фермаларында эшләүчеләрнең белемен күтәрү өчен түгәрәкләр оештырылды. Тәкәнеш районындагы 18 колхозда оештырылган түгәрәкләрдә 121 кеше, Саба, Яңа Чишмә, Ширәмәт районнарында оештырылган 24 түгәрәктә 681 кеше укый.

■ Арча районы финанс бүлеге работниклары коллективы ирекле страхование җыю планын 20 нче февральгә срогыннан элек 101 процент итеп үтәде. Хәзер районның барлык колхозларында да финанс планын тагын да арттырып үтәү өчен көрәш бара.

■ Ютазы районы, Уруссу авылында шушы елның 1 нче январеннан алып 15 нче февральгә кадәр Осоавиахим оешмасына 40 член кабул итеде, 23 кеше „Ворошиловча атучы" значогына, 31 кеше ГТО значогына нормалар тапшырды. Авылда ПВХО түгәрәге дә оештырылды.

■ Татстройматпромсоюзның кирпеч заводлары быел 16 миллион данә кирпеч эшләп чыгарачаклар. Әгерҗе районындагы „Ударник" һәм Кукмара районындагы „Бригадир" артельләренең заводлары иң соңгы техника буенча механикалаштырылдылар.

■ Татарстан Автомобильләр Идарәсенә быел газогенераторлы 40 автомобиль алына. Автомобильләр агач хәзерләү эшендә файдалану өчен Чаллы һәм Мамадыш районнарына җибәреләчәкләр.

■ Арча районының „Орнашбаш" колхозыннан 17 хуҗалык, „Октябрь Маса" колхозыннан 12 хуҗалык һәм „Авангард" колхозыннан 7 хуҗалык Бурят-Монголиягә күчәләр.

■ Кызыл Юл районыннан февраль аенда 70 ләп колхозчы хуҗалыгы Бурят-Монголия республикасы колхозларына күчеп киттеләр. Күчеп китүче иптәшләр—алдынгы колхозчылар.

КИНО-ЖУРНАЛНЫҢ ЧИРАТТАГЫ НОМЕРЫ

Союзкинохрониканың Казан студиясе кино-журналның чираттагы номерын экранга чыгаруга хәзерләнә. Бу 6 нчы номерлы журналга Казан станциясендә оборона көне, Ижевскийдагы мотозаводның конструкторлары—Рогожин һәм Зебзиев иптәшләр, Мари республикасы колхозыннан бер кадр алынды.

Шулай ук бу номерда Казан Хәрби Пехота училищесенең ату отличниклары, кавалерия мәктәбе һәм яшь авиомодельче Шуртальцев һәм башкалар төшерелде.

Журнал якын көннәрдә экранга чыга.

БЕЛДЕРҮ

— Бүген, 28 февральдә, кич сәгать 6 да Язучыларның Тукай исемендәге кабинетында шагыйрьләр секциясенең җыелышы була. Җыелышта Татарстанның XX еллыгына хәзерлек турында информация һәм яңа әсәрләр укулар булачак. *Секция.*

Җаваплы редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.

Зам. ответ. редактора И. УЗБЕКОВ.

„ГЛАВКИНОПРОКАТ" НЫҢ ТАТАРСТАН БҮЛЕГЕ

якын көннәрдә Татарстан АССР киноэкраннарына, „Мосфильм"дә эшләнгән

Ф. Панферов сценарийсы. Режиссер В. Строева һәм Г. Рошаль.

Баш рольләрдә артистлардан: Грибков, Куприянова, Самойлов, Соловьев, Жильцов, Оленев һәм башкалар.

Фильм хәзерге колхоз авылы тормышы турында сөйли.

исемле тавышлы художестволы яңа фильм бирә.

Өй түбәләреннән кар төшергәндә радио проводаларының масса күләмдә өзелүеннән шәһәрнең аерым районнары радио тыңлаудан мәхрүм ителәләр.

Шул уңай белән

ШӘҺӘР РАДИО ЧЕЛТӘРЕ

барлык йорт идарәләреннән, дәүләт йортларының һәм частный йортларның хуҗаларыннан,—йортларны ремонтлау һәм агарту-буяу, шулай ук өй түбәләреннән кар төшерү вактында

радио проводаларын өзүгә һич юл куймауларын сорый

Әгәр дә йортларны ремонтлау, агарту-буяу өчен радио проводалары комачаулаcалар, проводаларны вакытлы рәвештә алу өчен радиоузеллардан надсмотрщиклар чакырырга тәкъдим итә. Надсмотрщикларны Бауман һәм Молотов районнарында 21 нче, Сталин районында 15—22, Киров районында 12—40 яисә 21 нче, Ленин районында 22—31 телефоннары буенча чакырырга.

Шуның белән бергә, Шәһәр Радио челтәре барлык йорт идарәләренә һәм йорт хуҗаларына кисәтү белдерә:

Проводаларның өзелүе була калса, СССР Элемтә Наркоматының кагыйдәләре нигезендә, проводаларның өзелүеннән килгән бөтен зарар проводаларны өзүдә гаепле кешеләр өстенә төшә һәм алар Казан Шәһәр Советы Президиумының 1939 нчы ел, 8 нче апрель карары нигезендә 100 сумга кадәр штрафка яисә бер айга кадәр мәҗбүри эшкә тартылалар.

Радиоточкалары булган барлык гражданнардан,—үзләренең радиоточкаларының тиешле тәртиптә булуын күзәтеп торулары һәм радиоточкаларга кагылучы башка кешеләрнең саклык белән эш итүләрен таләп итүләре сорала.

ШӘҺӘР РАДИО ЧЕЛТӘРЕ.

26—1

Дәүләт Банкысы Татарстан Республика конторасының Шәһәр идарәсе барлык клиентларына белдерә:

1940 нчы елның II нче кварталында хезмәт хакы түләү һәм башка расходлар өчен кирәк булачак хәзер акча сумасына заявкалар шушы ел 1 нче мартка кадәр генә алына.

Барлык оешмаларның һәм учреждениеләрнең хәзердән үк Банк Конторасы Шәһәр идарәсенең тиешле оператив группаларыннан заявка бланкларын алулары һәм аларны тутырып, күрсәтелгән сроктан соңга калмыйча Банк Шәһәр идарәсенең кассовый план группасына бирүләре сорала.

Дәүләт Банкысы Татконторасының Шәһәр идарәсе.

25—2—1

ТАТНАРКОМСОБЕС

агротехниклар хәзерләү мәктәбенә,

III нче группа инвалидлардан шушы ел 1 нче мартка кадәр

УКУЧЫЛАР АЛА

Уку срогы 1 ел. Укучыларга стипендия, туклану һәм тулай торакта урын бирелә. Мәктәпкә керүчеләрдән кимендә 5 класс күләмендә белем сорала.

Документлар белән гариза җибәрү өчен адрес: Казан, Тукай урамы, 5, Татнаркомсобес. 351—3—3

Машиналар төзү заводы

җиңел һәм йөк автомобильләре САТЫП АЛА

41—54 һәм 16—22 телефоннары буенча яисә почта адресы буенча М. Ф. Шиховка мөрәҗәгать итәргә. 36 нчы почта бүлеге, почта ящиге 732.

373—5—1

Главаптекуправлениенең — Татарстан бүлеге —

Профсоюз урамындагы 26 нчы йортта (аптекалар үзәк складлары бинасына)

КҮЧТЕ

Телефоннар: управляющий 35—36, сәүдә бүлеге 61, Гомуми бүлек 8—20. 236—2—1

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Бүген һәм һәр көн РСФСР ның атказанган артисты орденлы

М. ЗОЛЛО

гастрольләре

Яңартылган репертуарда көлке номер:

„МӘЕТ КҮМҮ"

хайваннар һәм кошлар башкаруында һәм башка номерлар.

1 нче мартта көндез 12 сәгатьтә зур программа буенча

КӨНДЕЗГЕ ЦИРК УЕНЫ

Билетлар түбәнәйтелгән бәядән.

ЗОЛЛО ТИМЕР ЮЛЫ хәзерләнә.

Уен кич 8 дә башлана.

Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 3 кә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

КАЗАН ИТ КОМБИНАТЫ

эчәгечеләр, сугымчылар, обвальщиклар, жиловщиклар һәм обрядчиклар — хәзерләү буенча —

4 айлык курслар ача

Курсларга 18 дән 35 кә кадәр яштәге кешеләр алыналар. Укучыларга айга 115 сумнан 150 сумга кадәр стипендия бирелә. Казан, Тимер Юл урамы, 3, Казан Ит комбинаты (3 нче маршрут трамваеның Холодильник янында туктавы).

367—1

Завод хезмәткәрләрен һәм эшчеләрен урнаштыру өчен 5—6 ай срок белән

квартиралар, бүлмәләр һәм почмак урыннар КИРӘК

Казан, Островский урамы, 8, 16 нчы квартира. Ял көннәреннән башка һәр көн көндез 10 сәгатьтән 3 кә кадәр, Ф. Г. Асафовка мөрәҗәгать итәргә. 334—3—1

КАЗАН ИТ КОМБИНАТЫ БЕЛДЕРӘ:

Сую өчен терлекләр гомуми ял көннәреннән башка һәр көн чикләнмәгән санда

алына

372—1

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ

Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры бинасында

Бүген, 28 нче февральдә

ЗУР КОНЦЕРТ

Талон 79.

Уен башлана 9 сәгатьтә.

29 нчы февральдә

ИРЕК

Талон 80.

Уен 7 сәгать 30 минутта башлана.

Билетлар ТДАТ кассасында сатыла.

Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

2—1

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

28 һәм 29 нчы февральдә

ЛЕНИН

Бүген талон 111.

Коллектив рәвештә килү өчен заявкалар алына.

Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана.

Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

Киров районындагы

КУЛЬТУРА САРАЕНДА

ТДАТ спектакльләре

29 нчы февральдә

БИШБҮЛӘК

Талоннар 60 һәм 61.

Спектакль кич 8 дә башлана.

„ЭЛЕКТРО" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДУСЛАР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 6, 8, һәм 10 да.	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП
„ЧАТКЫ" 6, 8, 9-30 да.	ЗЕЛИМХАН
„ПИОНЕР" 10-50, 1, 2, 4-30, 7 һәм 9-30.	МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ" 4, 6, 8, 10 да.	БАЛТЫЙКЧЫЛАР
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	БЕЗ КРОНШТАДТТАН

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 732 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА. ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 805